6.2. Министерству внутренних дел по Республике Татарстан рассмотреть вопрос о недопущении случаев отделами полиции непредставления информации по запросам исправительных учреждений о вопросах бытового устройства лиц, освобождаемых из мест лишения свободы.

6.3. Управлению Федеральной миграционной службы России по Республике Татарстан совместно с исполнительным комитетом Совета Ассамблеи народов Татарстана рассмотреть возможность изыскания средств для материально-бытового обеспечения иностранных граждан и лиц без гражданства, содержащихся в специальном учреждении временного содержания иностранных граждан и лиц без гражданства УФМС России по Республике Татарстан, в том числе за счет добровольных пожертвований.

7. В целях правового просвещения жителей республики:

7.1. Министерству юстиции Республики Татарстан принять меры по дальнейшему совершенствованию работы в области обеспечения комплексного развития государственной системы бесплатной юридической помощи в Республике Татарстан, содействовать информированию граждан о возможностях получения бесплатной юридической помощи, выработать новые формы правового информирования и просвещения граждан, осуществлять мониторинг развития системы бесплатной юридической помощи и правового просвещения в Республике Татарстан.

7.2. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» распространять информацию о возможностях получения населением бесплатной юридической помощи и положительном опыте работы по правовому просвещению в муниципальных районах (городских округах) Республики Татарстан.

7.3. Органам местного самоуправления принять меры, направленные на организацию активного взаимодействия с различными категориями населения в вопросах развития правовой грамотности и правового просвещения жителей республики с применением различных форм работы и привлечением средств массовой информации, использованием опыта Уполномоченного, а также возможностей высших учебных заведений и их филиалов, юридических клиник при вузах, общественных организаций, профильных учреждений.

**Уполномоченный по правам человека**
**в Республике Татарстан** **С.Х.Сабурская**

г.Казань

Февраль, 2015 год

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ**

# 2014 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН САКЛАУ ТУРЫНДА

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

**ЭЧТӘЛЕК**

Кереш.............................................................................................63
Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау ..........................................64
Хезмәт хокукый мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын саклау.............................................................................................67
Торакка хокукны яклау.........................................................................73
Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукны яклау.........80
Социаль яклау һәм халыкны саклау....................................................87
Хезмәткә чакырылучыларның һәм хәрбиләрнең хокукларын яклау..............93
Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын яклау...............................................................................................96
Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкил эшчәнлегендә хокукый агарту...........................................................................102
Йомгак.............................................................................................106

# Кереш

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» гы 95 нче 2000 елның 3 мартында чыккан Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсенә ярашлы рәвештә, ел беткәннән соң өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкил (Алга таба – Вәкил) Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм иреген саклау турындагы докладны Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы прокурорына җибәрә.

Әзерләнгән доклад Вәкилгә килгән шикаятьләрне карау нәтиҗәләренә, тикшерү йомгакларына, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары мәгълүматларына, шулай ук Вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре биргән мәгълүматларга, хөкүмәтнеке булмаган хокук саклау оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белдерүләренә, республика ведомствоара комиссияләре материалларына һәм башка чыганакларга нигезләнә.

Югарыда күрсәтелгән материаллар нигезендә тормышның мөһим өлкәләрендә кеше хокукларын саклау белән бәйле хәл анализланды. Докладта шулай ук чакырылыш буенча хәрби хезмәткәрләрнең һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларның хокукларын саклау белән бәйле хәлгә дә бәя бирелде.

Докладның аерым бүлеге Вәкил һәм аның аппаратының хокукый аңлатуга булышлык итү буенча эшенә багышланды.

## Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау

Ел дәвамында Вәкилгә гражданнардан кергән шикаятьләр (башка мөрәҗәгатьләр), аларның нәтиҗәләренең эчтәлеге һәм аларга вазифаи затлар ягыннан җаваплар республика территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекен саклау һәм яклау буенча хәлне бәяләүнең бер чыганагы булып торалар.

2014 елда Вәкилгә 2982 мөрәҗәгать керде. Шулардан 1732 шикаять (башка мөрәҗәгатьләр) – язма яки электрон документ рәвешендә. 286 шикаять буенча бозылган хокукларны торгызу чаралары күрелде. Шәхси кабул итү вакытында 1250 мөрәҗәгать керде.

2014 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилгә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренең саны

1 нче таблица

| Күрсәткечләр | Мөрәҗәгатьләр саны |
|---|---|
| Барлык мөрәҗәгатьләр, шул исәптән: | 2982 |
| язмача яки электрон документ рәвешендә мөрәҗәгатьләр | 1732 |
| Телдән мөрәҗәгатьләр (кабул итү) | 1250 |

Гражданнарның иң күп шикаятьләре (шәхси кабул итүне дә кертеп), торакка, шул исәптән, торак-коммуналь хезмәт күрсәтү өлкәсендә хокукларны тормышка ашыру белән бәйле (788). Моннан тыш, гомуми структурада иң күп таралган мөрәҗәгатьләр – хокук саклау органнары хезмәткәрләренә шикаятьләргә (392), социаль тәэминат һәм халыкны социаль яклауга (265), мәҗбүри тоту урыннарда кешеләрне тоту шартларына (232), хезмәт мөнәсәбәтләрен саклауга (253), суд карарлары белән ризалашмауга (239) кагыла.

2014 елда 2013 ел белән чагыштырганда хезмәт мөнәсәбәтләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләр, (2014 елда – 253, 2013 елда – 127), хәрби хезмәткәрләр хокукларын тормышка ашыру белән бәйле сораулар арту (2014 елда – 103, 2013 елда – 42) бу тематикалар буенча актив эш алып бару белән аңлатыла. Мәсәлән, Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе белән берлектә 2014 елда гражданнарны өч тапкыр кабул итү үткәрелде. Хокук мөнәсәбәтләренең күрсәтелгән өлкәләре буенча дәүләт органнарыннан аларга мөрәҗәгать иткән кешеләрнең конституциячел хокукларын тормышка ашыру өчен зур инициатива күрсәтү таләп ителә.

2014 елда РФ Тикшерү комитетының Татарстандагы тикшерү идарәсе белән (5 кабул итү), Эчке эшләр министрлыгы белән (3 кабул итү), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе белән (1әр кабул итү) гражданнарны уртак кабул итүләр үткәрелде.

Вәкилнең дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе белән уртак кабул итүләре барышында 190 кеше кабул ителде.

2014 елда мөрәҗәгатьләрнең тематик структурасы

2 нче таблица

| | **Мөрәҗәгатьләр тематикасы** | **Мөрәҗәгатьләр саны** |
|---|---|---|
| 1. | Торакка хокук | 788 |
| 2. | Хокук саклау органнары хезмәткәрләренә зарлар | 392 |
| 3. | Социаль тәэминат һәм халыкны социаль яклау | 265 |
| 4. | Хезмәт мөнәсәбәтләре | 253 |
| 5. | Суд карарлары белән килешмәү | 239 |
| 6. | Мәҗбүри тоту урыннарында тоткыннарны тоту шартлары | 152 |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Медицина хезмәте күрсәтү | 121 |
| 8. | Миграция мөнәсәбәтләре | 105 |
| 9. | Хәрби хезмәткәрләрнең хокуклары | 103 |
| 10. | Суд карарларын үтәү | 57 |
| 11. | Җиргә хокукны яклау | 35 |
| 12. | Белемгә хокук | 28 |
| 13. | Хокукый мәгълүмат бирү мәсьәләләре | 146 |
| 14. | «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы эше мәсьәләләре | 130 |
| 15. | Башка мөрәҗәгатьләр | 167 |
| | Барысы | 2982 |

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү эшенә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкилнең аерым шикаятьләр яки тикшерү чаралары буенча йөкләмәләрен үтәп, бу юнәлештә беренче елларын гына эшләмәүче җәмәгать ярдәмчеләре дә үз өлешен кертте. Моннан тыш, җәмәгать ярдәмчеләренең үзләренә генә дә 2014 елда 2136 мөрәҗәгать керде. Граждан һәм кешенең бозылган хокукларын һәм иреген торгызуда үз эшчәнлекләрен җәмәгать ярдәмчеләре хокук саклау органнары, җирле үзидарә органнары һәм гражданлык институтлары белән тыгыз элемтәдә торып башкардылар.

2013 елның 5 августыннан Вәкил Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы эшчәнлеген тормышка ашыра. 2014 елда системада 21558 гариза урнаштырылды. Иң күп белдерүләр «Территорияләрне төзекләндерү» (7646), «Юл хәрәкәтен оештыру» (6652) төрләре буенча керде. Докладта югарыда күрсәтелгән темаларга кагылышлы белдерүләр дә иң киң таралган шикаятьләр иде. «Торак-коммуналь хезмәтләр» төре буенча 2014 елда 1654 белдерү, «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча – 433, «Уңайлы тирәлек» төре буенча – 358 белдерү басылды.

Модерация йомгаклары буенча 1753 шикаять компетентлы орган аның адресына гражданнан яки төркемнән теге яки бу проблеманы хәл итү зарурлыгы турында кергән мәгълүматны карау буенча тиешле чаралар күрмәгән өчен, кабат эшләргә кайтарылды.

Гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләре белән беррәттән, мәгълүмат системасындагы мәгълүматларны анализлау икенче ел инде Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм иреген саклау һәм яклау буенча хәлгә бәя бирүдә мәгълүмат чыганагы булып тора.

## Хезмәт хокукый мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын саклау

Узган ел бөтен Россиядә икътисадта тышкы чикләүләр аркасында килеп туган үзгәрешләр белән истә калды. Шул уңайдан хәзерге вакытта хакимият органнары һәм бизнесның хезмәт базарында тискәре хәлләргә кул куймас өчен җаваплылык зонасы арта.

Гражданнарның хезмәт хокукларын тормышка ашыру өчен аларны саклауга һәм яклауга юнәлтелгән чаралар тупланмасы кулланыла. Күрелгән чараларга карамастан, кеше хокукларын һәм иреген хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә саклау һәм яклау тырышлык таләп итә.

2015 елның 1 гыйнварына республика предприятиеләрендә хезмәт хакы буенча бурыч 47,822 млн. сум тәшкил итте. Статистик мәгълүматлар шуны дәлилли: хезмәт хакы буенча бурыч нигездә предприятие һәм оешмаларның акчасы булмаганлыктан җыела.

Гражданнарның хезмәт хокукларын саклау ысулларын анализлаганда, шул факт үзенә җәлеп итә: Суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе бүлекчәләре тарафыннан 2014 елда хезмәткәргә тиешле хезмәт хакы һәм башка түләүләр буенча 181 миллион 694 мең сумлык бурычны кире кайтару буенча 8 043 башкарма эш ябылган. 2013 елда бу төр буенча 218 миллион 545 мең сумлык 17423 башкарма эш

ябылган булган. Шулай итеп, Вәкил фикеренчә, хезмәткәрләр алдында хезмәт хакы буенча бурычларны түләүдә уңай үзгәрешләр күзәтелә.

Шуның белән беррәттән, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматлары буенча тоткарланган хезмәт хакы бары дәүләт хезмәт инспекторлары тикшергәннән соң гына түләнгән хезмәткәрләр саны арткан. (2014 елда андый хезмәткәрләр саны 12896 кеше тәшкил итте, (гомуми түләүләр 313 миллион 039 мең сум, 2013 елда 9082 хезмәткәргә 165 миллион 340 мең сум тәшкил итте). Шул ук вакытта, контроль орган мәгълүматларына ярашлы рәвештә, ел дәвамында хезмәт инспекторларына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм табышларны легальләштерү буенча территориаль ведомствоара комиссияләреннән эш хакы түләү буенча бурычы булган хуҗалык итүче субъектлар турында мәгълүматлар кермәгән.

Контроль-күзәтчелек органнары ачыклаган эш хакы түләү буенча хокук бозулар арту күзәтелгәндә, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм табышларны легальләштерү буенча территориаль ведомствоара комиссияләре намуссыз эш бирүчеләргә карата килешмәүчәнлек позициясен алырга тиеш. Практика шуны күрсәтә: контроль-күзәтчелек органнары тикшергәннән соң, күп очракта эш бирүчеләр эш хакы буенча бурычларын түләргә акча таба. Бурыч күләменең артуына юл кую, киресенчә, законлы көченә кергән суд карары белән дә хезмәткәрнең түләнмәгән эш хакын алачагына гарантия бирми. 2014 елда суд приставлары-башкаручылары гомуми суммасы 116,963 миллион сумлык (бер башкару эшенә уртача 16815 сум) 6595 башкарма эшне япкан булса, бурычлының бурыч түләү өчен милке булмау турында башкару документын кире кайтару сәбәпле, 193 эш ябылган.

Кайбер оешмаларда эш хакы буенча бурычның узган ай белән чагыштырганда, тиз артуын күздә тотып, эш хакы буенча бурычларның гомуми күләмен киметү генә түгел, бурычлы оешмаларның санын да киметүне максат итеп куярга кирәк.

Республикада элеккечә үк хезмәткәрне эшкә алганда документны дөрес тутырмау, хезмәт килешүен дөрес төземәү, хезмәт килешүен туктату процедурасы белән бәйле хәлләр еш очрый. Мондый намуссыз эш бирүчеләргә карата чаралар күрелми, кызганычка каршы, күрсәтелгән кимчелекләр тикшерелгәннән соң гына бетерелә.

«ТКП» ширкәте хезмәткәрләре шикаяте буенча Вәкил аппараты үткәргән тикшерү барышында хезмәт законнарында каралмаган, хезмәткәрләр белән ашыгыч хезмәт килешүләре төзү фактлары ачыкланды. Моннан тыш, хезмәткәрләр белән хезмәт килешүләрендә вакыты күрсәтелмәгән сынау шартлары турындагы шартлар язылган, ә хезмәт килешүе туктатылу турында хезмәткәрләр эштән китү көнендә генә кисәтелгән. Тикшерү турындагы мәгълүматны без Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясенә җибәрдек, нәтиҗәдә контроль орган җитәкчене административ җаваплылыкка тартты һәм кимчелекләрне бетерү турында кисәтү кәгазе бирде.

Узган елда хезмәткәрләр штатын яки санын кыскарту, хезмәт килешүләрен өзү көтелүе турында карарлар кабул иткән эш бирүчеләрнең саны артты. (2013 елда мәшгульлек хезмәте органнарына 943 шундый белдерү керсә, ул 2014 елда ул – 1063). Оешмалардан 2014 елда хезмәткәрләрнең штаты кыскару аркасында эштән җибәрелгән гражданнарның хокукларын саклау буенча Вәкил һәм аның аппараты тикшерүләр үткәрде.

Тикшерүләр барышында эштән азат ителгән эшмәкәрләргә гарантияләр, компенсацияләр һәм башка түләүләр бирү белән бәйле хокук бозулар ачыкланды. Шулардан иң киң таралганнары – соңыннан куелган срок буенча кыскартканда тиешле барлык сумманы да түләмәү, тиешле сумманы тоткарлаган очракта Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 236 нчы маддәсенә ярашлы рәвештә һәр тоткарланган көн өчен компенсация түләмәү. Кайбер очракларда эштән җибәрелә торган хезмәткәрләр үзләренең хезмәт хокукларын яклаганда, хезмәт килешүе булганнарга

караганда азрак якланган. Мәсәлән, «Авиакомпания Татарстан» җәмгыяте, эшләүче хезмәткәрләренә карата эш хакы буенча бурычын түләп, берничә хезмәткәрне, эштән азат итү көнендә акчаны тулысынча түләмичә генә кыскарткан. Әлеге предприятие җитәкчелегенә карата бала караган өчен пособие түләү буенча да дәгъвалар бар.

Вәкил фикеренчә, тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм табышларны легальләштерү буенча территориаль ведомствоара комиссияләргә мәшгульлек органнары белән бергә, эш хакы буенча һәм эш бирүче-бурычлы хезмәткәрләр санын яки штатын кыскарту турында карар кабул иткән очракларда, эштән җибәрелә торган хезмәткәрләргә түләү өлешендә бурычларга юл куйган, шулай ук бала ялында булган хезмәткәрләргә пособие түләмәгән хуҗалык итүче субъектларны контрольдә тотарга кирәк.

Тагын бер проблемалы аспект – эштән җибәрелә торган хезмәткәрләрнең үз эш сыйфатларына туры килгән эш яки вакантлы вазифа тәкъдим итү процедурасының ачык булмавы ( тәкъдимнәрнең язма рәвештә бирелмәве). Россия Федерациясе Хезмәт кодексында хезмәткәрләр штаты кыскару белән бәйле эштән җибәрүләр турында карар кабул иткәндә, хезмәткәрләргә карата хезмәткәрләр квалификациясенә туры килә торган эшләр яки вакантлы вазифалар тәкъдим итү формалары һәм ысулларына кагылышлы күрсәтмәләр күрсәтелмәгән. Икенче яктан, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 маддәсе 3 өлешендә каралган, вазифасы кыскартылган хезмәткәргә эштән җибәрү көненә кадәр күрсәтелгән вакансия таләпләренә җавап бирүче эш тәкъдим итү эш бирүченең бурычы, бу индивидуаль хезмәт бәхәсләре килеп чыккан очракта тиешле мәгълүматлар булу бурычын йөкли.

Тикшерүләр барышында төп хезмәткәр булмаган вакытта хезмәткәргә эш тәкъдим ителмичә, сан яки штат кыскару белән бәйле очраклар да ачыкланды. Шунысын да әйтергә кирәк, суд практикасы бу очракта бер яклы гына түгел. Шуның белән бергә, төп хезмәткәр булмаган чакта (мәсәлән, ул бала ялында булган вакытта) эш тәкъдим итү эштән китә торган хезмәткәргә

яңа эш эзләгәндә сайлау мөмкинлеген киңәйтер иде. Хәзер хезмәт базарында эшче көчләр сорауга структур туры килмәү саклана, ә массакүләм мәгълүмат чараларында эшсезлек дәрәҗәсенә карата пессимистик фаразлар белдерелә.

Вәкил фикеренчә, оешмада хезмәткәрләр саны яки штат кыскару белән бәйле рәвештә, хезмәт килешүен өзү турында карар кабул ителгән хезмәткәрләргә карата хокукларын судтан тыш торгызу механизмнарының берсе – хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр эшчәнлеге. Аларның индикатор күрсәткечләре дәгъва гаризалары санын киметүдә куланыла алыр иде.

Хезмәт килешүен өзү турында карар кабул ителгән хезмәткәрләрнең хезмәт хокукларын яклауда Татарстан Министрлар Кабинетының 2013 елның 9 августындагы карары белән расланган «2014-2020 елларга халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү һәм хезмәт миграциясен көйләү чараларын тормышка ашыру» программасында каралган предприятие (оешма) ябылу яки хезмәткәрләр саны яки штат кыскарту планлаштырылган предприятиеләрдә (оешмаларда) махсуслашкан консультация пунктлары оештыру мөһим әһәмияткә ия. Хезмәткәрләрне эштән җибәргәндә хезмәт законнарын бозу турында күмәк шикаятьләр килгән очракта мәшгульлек органнары хезмәткәрләре аңлатмалар белән генә чикләнмичә, мондый фактлар турында күзәтчелек органнарына һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм табышларны легальләштерү буенча комиссияләргә мәгълүматлар тапшыра ала.

Вәкил, эш бирүчеләрнең куркынычсыз эш шартларын тәэмин итүе буенча республиканың күзәтчелек һәм контроль органнары, тармак министрлыклары, прокуратура органнары, тикшерү органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең системалы рәвештә эш алып баруын билгеләп үтә. Кешеләр тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч булган оешмалар эшен туктату буенча чаралар күрелде. Болар: «СпецСтрой» җәмгыяте (Питрәч районы), «Лира» ширкәте (Казан шәһәре), «Аэропорт Бугульма» җәмгыяте (Бөгелмә муниципаль районы), «Предприятие жилищно-

коммунального хозяйства» җәмгыяте (Казан шәһәре). Республикада бәхетсезлекләр аркасында җитештерүдә үлем очраклары кимеде. Дәүләт Хезмәт инспекциясе оператив мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасында җитештерүдә 2014 елда 68 кеше вафат булган, 2013 елда һәлак булучылар саны 103 гә җиткән иде.

Кызганычка каршы, җитештерүдә үлем белән беткән имгәнүләр кимү тенденциясе анык булып күренми. Аерым алганда, ел дәвамында күзәтелә торган чорларда (квартал, яртыеллык), аерым өлкәләрдә (финанс эшчәнлеге, мәгариф) һәлак булучы хезмәткәрләр саны арткан. Җитештерүдә үлем яки авыр имгәнүләргә китергән сәбәпләр үзгәрешсез кала: эшләрне канәгатьләнмәслек оештыру, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу, төзек булмаган машина һәм җиһазлардан файдалану, хезмәткәрнең индивидуаль саклану чараларын кулланмавы. Хезмәт инспекторларының статистик мәгълүматлары буенча, хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибен һәм хезмәт дисциплинасын бозуы аркасында җитештерүдә үлем белән беткән бәхетсезлек очраклары өлеше, гомуми санның 6,2 процентын гына тәшкил итә.

Хезмәтне саклау өлкәсендә хокук бозулар элеккечә үк латент характерда булу борчу уята. Хезмәт куркынычсызлыгы шартлары буенча чаралар күрелмәү турында хезмәткәрләрнең гаризалары, күзәтчелек органнарына һәм судларга, хезмәт хакын вакытында түләмәү турындагы мөрәҗәгатьләргә караганда сирәгрәк килә. Җинаять һәм административ җаваплылыктан куркып, зыян күргән хезмәткәргә законда каралган түләүдән качып, кайбер эш бирүчеләр җитештерүдәге бәхетсезлек очракларын яшереп калдыруга баралар.

Вәкил фикеренчә, латентлык дәрәҗәсен кимeтү хезмәтне саклау өлкәсендә хокук бозулар турында мәгълүмат чыганакларын арттырганда гына мөмкин. Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы шундый каналларның берсе була алыр иде.

Лаеклы хезмәт хакы, хезмәтне саклау һәм халыкның мәшгульлеге – болар 2014-2018 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары

буенча стратегия положениеләренә нигезләнгән хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә халыкның уңай тормышы өчлеген тәшкил итәләр. Төбәк үсеше өчен әһәмиятле бизнесны яклау һәм шул исәптән, хезмәт базарында эшкә яраклы халыкның аерым бер өлеше мәшгуль булуын исәпкә алып, хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокуклары бозылуга юл куярга ярамый.

## Торакка хокукны яклау

Республикада торак төзү программаларын тормышка ашыруга җитди игътибар бирелә. Төзү темплары Россия Федерациясенең башка төбәкләре өчен үрнәк булып тора.

2014 елда, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь торак хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2399 мең квадрат метр торак, шул исәптән социаль ипотека программасы буенча – 383,4 мең квадрат метр, күпквартирлы инвестиция торагы программасы буенча – 1017,1 мең квадрат метр (10 мең квартирдан артык), аз катлы торак программасы буенча – 1096,9 мең квадрат метр (9971 аз катлы торак йорт ) сафка бастырылган.

Төзүчеләрнең тырыш хезмәте нәтиҗәсендә яңа квартираларны ташламага ия гражданнар: 377 Бөек Ватан сугышы ветераны, 67 яшь гаилә, 37 күп балалы гаилә, 309 әти-әнисез калган ятим бала алган.

2014 елда «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру – 2017 елга исәпләнгән экономкласс торагын төзү башланды.

Шуның белән бергә, татарстанлыларны, бигрәк тә халыкның социаль яктан аз якланган вәкилләрен торак белән тәэмин итү көнүзәк тема булып кала бирә.

Торак биналары белән тәэмин итмәү турындагы шикаятьләр Вәкилгә килгән хатлар арасында берничә ел рәттән иң киң таралганы булып кала. Узган елда авыр формадагы хроник авырулар белән авыручы инвалидлар мәнфәгатьләрен яклап бирелгән мөрәҗәгатьләрне аерып әйтергә була.

Казан шәһәрендә яшәүче Вәкил адресына авыр формадагы хроник авыру белән авыручы инвалидка чираттан тыш торак бирүдән законсыз баш тартулары мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Аңа, торакка чиратка 2005 елның беренче гыйнварыннан соң баскан бу төр гражданнарга торак субсидиясе бирү тәртибе эшләнмәүне сәбәп итеп, торак бирүдән баш тартканнар.

Шул вакытта авыр формадагы хроник авыру белән авыручы инвалидларны социаль найм килешүләре буенча торак белән тәэмин итү практикасы да бар.

Казан шәһәре башкарма комитеты фикеренчә, авыр формадагы хроник авырулы инвалидларга торак бирү җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре биргән очракта гына мөмкин. Шул ук вакытта 2014 елда җирле үзидарә органы тарафыннан югарыда аталган гражданнарга социаль найм килешүе буенча суд карарлары нигезендә 8 торак бирелгән.

Авыр формадагы хроник авыру белән авыручы гражданнарны торак белән тәэмин иткәндә дөрес карарлар кабул итмәү бу төр гражданнарга карата социаль гаделсезлеккә китерә.

Россия Федерациясе Торак кодексында бу төр гражданнарның социаль найм килешүе буенча торак алырга хокукы каралуын исәпкә алып, торак субсидиясе генә бирү аларның хокукларын кыса дип карарга кирәк.

Вәкил, авыр формадагы хроник авырулар белән авыручы инвалидларны социаль яклау чаралары турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында өстәмә рәвештә милек хәлен исәпкә алып, (закон нигезендә аз тәэмин ителгән дип танылган инвалидлар),социаль найм килешүе буенча инвалидларга чираттан тыш торак бирү хокукын карарга кирәк дип саный.

Ятим һәм әти-әнисе ярдәменнән мәхрүм калган балаларның торакка хокуклары, аерым алганда, мохтаҗларны торак шартларын яхшырту өчен исәпкә бастырганда хокуклары тиешенчә үтәлми.

2014 елда Вәкил адресына 23 яшькә җитүне сәбәп итеп торак шартларын яхшырту өчен исәпкә бастырудан законсыз баш тарту, ятим балаларны үзвакытында торак буенча исәпкә алмау белән бәйле мөрәҗәгатьләр керде.

Әйтик, Вәкилгә, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче торак алучылар реестрына үзвакытында исәпкә бастырмау мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Гариза бирүче үзе суд карары буенча 2013 елның октябреннән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ кеше сыйфатында исәптә торган. Шулай булса да, гариза бирүченең документларын Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы реестрына кертү эшен Яр Чаллы шәһәре башкарма комитеты суд карары буенча бары 2014 елда гына тормышка ашырган.Җирле үзидарә органнарының документларны Мәгариф һәм фән министрлыгына тиз генә җибәрмәве аркасында гариза бирүче торак алучылар реестрына бары 2014 елның августында гына кертелгән.

Узган 2014 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына карата ятим балаларны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы сыйфатында торак буенча исәпкә алуга хокукларын тану турында суд актлары буенча 8 үтәү эше кузгатылган.

2014 елда суд практикасын анализлау шуны күрсәтте, гариза бирүчеләрнең судларга мөрәҗәгать итүенең бер сәбәбе – ятим балаларның шәхси эшен алып барганда һәм торак алучылар реестрына кертү өчен документларны кабат җибәргәндә ятим балалар өчен мәгариф оешмалары, ятим балалар өчен социаль тәэминат учреждениеләре һәм җирле үзидарә органнары арасында үзара аңлашу булмау.

Вәкил фикеренчә, ятим балаларның хокуклары бозылуга юл куймау максатыннан, ятим балалар өчен мәгариф оешмаларына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренә муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары белән берлектә Мәгариф һәм фән министрлыгына торак алу

реестрына кертү өчен мәгълүмат җибәрелмәгән ятим балаларне ачыклау өчен ятим балаларның шәхси эшләрен тикшерүне үткәрергә кирәк.

Вәкил адресына гражданнардан аварияле торак фондыннан күчерүгә, аерым алганда, яшәү өчен яраксыз дип табылган һәм төзекләндерү мөмкин булмаган күпквартирлы йортларда яшәүче гражданнарны социаль найм килешүе нигезендә күчерүгә кагылышлы мөрәҗәгатьләр килә. Җирле үзидарә органнары федераль законда авария хәлендәге торак йорттагы торак бүлмәләрен хосусыйлаштыру тыелуын исәпкә алмыйча, судларның гариза бирүченең муниципаль торак бүлмәсен хосусыйлаштыруга хокукын тануы турындагы карарларына сылтыйлар.

Социаль торак булмау проблемасы яңа түгел. Ул электә Вәкилнең еллык докладларында күтәрелгән иде. Шуның белән бергә, муниципаль берәмлекләрнең муниципаль торак фондында буш торган яки азат ителгән квартиралар исәбенә социаль найм килешүе буенча торак бүлмәләре бирүне оештыруда җитәрлек эшләмәвен дә әйтми булмый. Үткән елда Вәкил һәм аның аппараты республиканың берничә шәһәрендә тиешле тикшерүләр үткәрде. Тикшерү барышында конкрет торак биналарын бүлү, шулай ук муниципаль торак фондын исәпкә алу буенча да кимчелекләр ачыкланды.

Казан, Яр Чаллы, Әлмәт шәһәрләре башкарма комитетлары тарафыннан гражданнарны социаль найм килешүе буенча яшәп торган торак бүлмәләреннән чыгару турында судка дәгъвалар бирелү очраклары ачыкланды. Дәгъваларны канәгатьләндергән судлар карарларыннан соң да бушаган торак бүлмәләрен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган гражданнарга бирү буенча чаралар озак вакытлар кулланылмаган.

Әлмәт шәһәрендә 2013 елның июлендә бушаган муниципаль торак фонды квартирасы Вәкил 2014 елның апрелендә үткәргән тикшерүдән соң гына бирелгән.

Чаллы шәһәрендә Мәскәү урамындагы муниципаль тороактан суд карары нигезендә квартираны алып торган кеше һәм аның гаилә әгъзалары 2014 елның февралендә чыгарылган. Тикшерү үткәрү вакытына (2014 елның

сентябре) бу квартираны социаль найм килешүе буенча бирү буенча чаралар күрелмәгән, аның өстәвенә, торактан чыгарылган гражданнарны теркәү исәбеннән төшерү турында гариза да бирелмәгән.

Казан шәһәренең башкарма комитеты 2014 елның май, июнь, сентябрь айларында Центральная урамында элеккеге хуҗаларын чыгару аркасында буш торган квартирада ремонт эшләре үткәрү турында мәгълүмат җибәрде. Эшне конкрет үтәү вакыты һәм социаль найм килешүе буенча квартира бирү вакыты турында белешмәләр бирелмәде.

Хуҗасы вафат булу сәбәпле буш квартира барлыкка килү ачыклангач, 2013 елның ноябрендә Лениногорск муниципаль районы башкарма комитеты Чайковский урамындагы азат ителгән торак мәйданын алырга теләүчеләрне таба алмаган. Алар бу хакта Вәкил адресына 2014 елның июлендә квартирага хуҗа табу турында өстәмә хәбәр ителәчәге турында мәгълүмат җибәрде. (Мәгълүматлар килмәде).

Муниципаль берәмлекләрдә торак фондын исәпкә алу, муниципаль торак базасын формалаштыру, торак фондын инвентаризацияләү буенча комиссияләр эше төрле дәрәҗәдә алып барыла.

Муниципаль торак фондында озак вакытка квартирларның буш булып та, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак бирү буенча тиешле чаралар күрелмәү халыкның аерым катлавының торакка хокукын тормышка ашыру җитәрлек дәрәҗәдә булмавын дәлилли. Торак биналарын исәпкә алганда муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә тиешле норматив актлар чыгарып, муниципаль торак фондының буш квартира һәм бүлмәләрен ачыклау һәм алга таба аларны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга бирү буенча даими эш алып бару максатка ярашлы булыр иде.

Коммуналь хезмәт күрсәтү өлкәсендә коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфаты, алынган хезмәтләргә акча күчерү, шул исәптән, «гомум йорт ихтыяҗлары» маддәсе буенча, күпквартирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның мәгълүмат бирүе, күпквартирлы йортлар белән идарә итү килешүләренең гамәлдәге законнарга

туры килүе, коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләү көнүзәк мәсьәләләр булып кала. Вәкил һәм аның аппараты тарафыннан бу тематика буенча даими рәвештә тикшерү чаралары үткәрелә.

Вәкил адресына гражданнардан җылы бирүне «Таттеплосбыт» һәм «ТГК Уруссинская ГРЭС» җәмгыятләре тәэмин иткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә җылы өчен гражданнардан түләү артуны киметү өчен субсидияләр алу белән бәйле мөрәҗәгатьләр керә.

Гражданнар шикаятьләренең бер сәбәбе: халыкның максатчан субсидия бирү һәм исәпләү тәртибе һәм шартлары турында аз белүе. Моннан башка, гаиләнең җан башына уртача айлык кеременең максималь күләме 30 мең булудан тыш, исәпләгәндә торак-коммуналь хезмәтләр өчен факттагы түләү күләме, торак-коммуналь хезмәтләренә түләгәндә алынган субсидияләр күләме һәм агымдагы айга субсидия-ташлама суммалары исәпкә алына. 2014 елда Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча 33112 очракта максатчан субсидия исәплəгәндә буш (нулевой) нәтиҗә теркәлгән.

Төрле инстанцияләргә шикаятьләр җибәрүне исәпләүдә калькуляция ярдәме алыштыра алыр иде. Мәсәлән, интернет челтәрендә максатчан субсидияне электрон калькулятор белән исәпләүне урнаштырып булыр, аннан кешеләр файдалана алыр иде.

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын саклау һәм яклауны анализлау, идарәче оешмаларның күпквартирлы йортларда яшәүчеләрнең персональ мәгълүматлары белән эшләү буенча агымдагы эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләрнең дә аерым игътибарга лаек икәнен күрсәтте.

Агымдагы эшчәнлекне тормышка ашырганда йортлары идарәче оешма карамагында булган яшәүчеләр – гражданнарның персональ мәгълүматларына ия булуны тормышка ашырганда, идарәче оешма аларны эшкәрткәндә кеше һәм граждан хокукларын һәм иреген, шул исәптән, шәхси тормыш, шәхси һәм гаилә серләре кагылсызлыгы хокукын яклауны тәэмин

итәргә тиешле персональ мәгълүматлар операторы вазифасын үз өстенә ала. Узган елда Вәкил һәм аның аппараты «Персональ мәгълүматлар турында» 152-ФЗ нче 2006 ел 27 июльдә чыккан федераль закон таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча Казан, Бөгелмә, Баулы, Алабуга, Әгерже, Лаеш шәһәрләре идарәче оешмаларын тикшерде.

Берничә идарәче оешмаларда субъектның персональ мәгълүматларны өченче затларга тапшыру буенча язмача ризалыгы булмау факты ачыкланды, шул ук вакытта мәгълүматларны өченче затларга тапшыру булган. Шуның белән бергә, гражданнарның персональ мәгълүматларын язмача ризалыктан башка гына өченче затларга тапшыру законда тыелган.

Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә бурычлары булган яшәүчеләр турында мәгълүматлар таратуда чагылган персональ мәгълүматлар конфиденциальлеге таләпләрен бозу очраклары ачыкланды. Бурычлылар исемлегендә булган, бурычлары законлы көченә кергән суд акты белән расланмаган гражданнар да бу исемлеккә кергән.

Коммуналь хезмәтләр өчен бурычы булган күпквартирлы йортларда яшәүчеләргә белешмәләр һәм күчермәләр бирүдә идарәче оешмаларның баш тарту очраклары ачыкланды. Торакчыларның мондый карарлары «Персональ мәгълүматлар турында» федераль закон таләпләрен үтәмәүләре белән бәйле. Мәсәлән, «Азино-1» торак милекчеләре ширкәте Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 328 нче маддәсенә таянган, аңа ярашлы рәвештә бер як йөкләмәләрен үтәмәсә, икенче як үз йөкләмәләрен үтәүне туктатырга хокуклы. Килешү шартлары буенча хокукка сылтап, идарәче оешма закон буенча үтәлергә тиешле вазифалары турында “оныткан”. Нәтиҗәдә тикшерү материаллары чаралар күрү өчен прокуратура органнарына җибәрелде. Казан шәһәре прокуратурасы Вәкил позициясе белән килеште һәм «Азино-1» торак милекчеләре ширкәте идарәсе рәисенә карата карар чыгарды.

Персональ мәгълүматлар белән эшләгәндә агент килешүләрен файдаланучы идарәче оешмаларны персональ мәгълүматлар операторлары

реестрында теркәү очраклары булмау очраклары ачыкланды. Шуның белән бергә, яшәүчеләрнең персональ мәгълүматлары белән (саклау, бетерү, персональ мәгълүматларны юкка чыгару) кайбер операцияләрне үткәрү вазифасыннан тайпылу очраклары булды.

Җирле үзидарә органнарына идарәче оешмаларның персональ мәгълүматларны эшкәртү өлкәсендә хокук бозулар турындагы мәгълүматны контрольгә алырга, шулай ук, агент килешүләре (башка килешүләр) нигезендә персональ мәгълүматлар белән эшләүдә читтән оешмалар җәлеп итүче идарәче оешмаларны персональ мәгълүматлар операторлары реестрына кертү, вазифаларын үтәмәгән очракта мәгълүматларны күзәтчелек органнарына тапшыру кирәк.

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә докладта яңгыраган проблемалы хәлләр масштабы һәм проблеманың үткенлеге буенча аерыла, әмма аларның һәркайсысы татарстанлыларга кагыла һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан игътибар сорый.

## Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукны яклау

2014 елда Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсендә халыкның сәламәтлеген ныгыту, гражданнарның сәламәтлеген һәм тормышын саклау буенча чаралар нәтиҗәлелеген күтәрү буенча эш дәвам итте.

727,4 миллиард сум күләмендә ресурслы тәэмин итүне күздә тоткан «2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы тормышка ашырыла.

Казан шәһәрендә радиоактив йодны кулланып, калкансыман биз яман авыруын дәвалау өчен радионуклид терапиясе бүлеге, Түбән Кама һәм Әлмәттә филиаллары булган Кан бирү үзәге ачылды.

2014 елда барлыгы сәламәтлек саклау учреждениеләре төзүгә, төзекләндерүгә һәм капиталь ремонт үткәрүгә Татарстан бюджетыннан 1,5

миллиард сумга якын акча бүленде. «2012–2016 елларга Татарстан Республикасы халкына башлангыч медико-санитар ярдәмен камилләштерү» программасы буенча 78 яңа модульле ФАПлар төзелде.

Беренче балалар хосписы ачылды, ул Россиядә балалар өчен икенче стационар хоспис булып тора һәм беренче коммерциячел булмаган шәхси медицина учреждениесе буларак теркәлде.

Республикада баш мие кан әйләнеше бозылган авырулар өчен 17 неврология бүлекләре (кан тамырлары үзәкләре) эшли. Төзелгән инфраструктура үзвакытында госпитализацияләүне тәэмин итәргә һәм махсуслашкан медицина ярдәме күрсәтергә мөмкинлек тудыра.

Заманча технологияләрне кулланып халыкка ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү 7 югары технологияле медицина үзәкләре шартларында 31 муниципаль берәмлектә оештырылган. Болар – «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика клиник хастаханәсе», «2нче республика клиник хастаханәсе», «Төбәкара клиник-диагностика үзәге», Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе», Яр Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина хезмәте хастаханәсе», «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте һәм Әлмәт шәһәре медицина оешмасы, «Түбән Кама үзәк район күп профильле хастаханәсе».

Дүрт ел дәвамында рәттән республикада халыкның табигый артуы күзәтелә. 2014 елда ул 9730дән артык кешене тәшкил итте.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы үз карамагындагы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эчке сыйфат контролен оештыруга принципиаль якын килүләр формалаштыру бурычын куйды.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт органы мәгълүматларына караганда, 2014 елда 8 пилот сәламәтлек саклау учреждениеләрендә (2 республика учреждениесе, 4 шәһәр учреждениесе, 2 үзәк район хастаханәсе) менеджмент сыйфаты системасын кертү тормышка ашырылган.

Үз чиратында 2014 елда массакүләм мәгълүмат чараларында тиешенчә

медицина ярдәме күрсәтмәү фактлары киң яктыртылды. (Бала үлү, авырлы хатынның баласы үлү, Яр Чаллы шәһәрендә Кама балалар медицина үзәгендә сәламәтлеккә авыр зыян салу, Казан шәһәренең «2 нче шәһәр клиник хастаханәсе»ндә, Азнакай үзәк район хастаханәсендә ашыгыч ярдәм күрсәтү станциясендә пациентлар үлү), болар – прокуратура һәм тикшерү органнарына тикшерү үткәрү предметына әверелде. Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстандагы Тикшерү идарәсе мәгълүматлары буенча, 2014 елда сыйфатсыз медицина ярдәме күрсәтү белән бәйле хәбәрләр буенча 42 җинаять эше ачылган.

Суд практикасын анализлау шуны күрсәтте, медицина ярдәме күрсәтү сыйфаты гражданнарның медицина учреждениеләренә дәгъва таләпләре белдерүнең бер сәбәбе булып тора. Мәсәлән, «Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе»ндә, эксперт заключениесенә ярашлы рәвештә, дәгъвачыга медицина ярдәме күрсәткәндә диагностика процессын бозу ачыкланган, бу үзвакытында диагноз куюны кыенлаштырган.

Татарстанлы «АК Барс-Мед» иминият компаниясенә медицина ярдәме күрсәтү сыйфатын билгеләү буенча экспертиза үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Экспертиза нәтиҗәләре буенча, «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе»нең көчле тәэсир итүче «трамадол» препаратын куллanудан баш тартуы ачыкланган, бу кат-кат «Ашыгыч ярдәм» чакыруга китергән, билгеләнгән дәвалану вакытын арттырган.

Сәламәтлек саклауга хокуклар бозылу турында Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге индикатив күрсәткечләре структурасында Спасс, Биектау, Лениногорск, Минзәлә, Нурлат, Питрәч муниципаль районнарында халыктан килгән нигезләнгән шикаятьләрнең югары күрсәткечләре дәлилли.

Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте Территориаль фонды мәгълүматлары буенча, гражданнарга түләүле медицина хезмәтләре,

дәүләт гарантияләре программасы чикләрендә күрсәтелә торган түләүсез медицина хезмәтен түләүле медицина хезмәте күрсәтүгә алыштыру белән бәйле проблемалар бар.

Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте Территориаль фонды Татарстан Республикасы Хисап палатасы белән берлектә үткәргән медицина оешмаларын тикшерүләр нәтиҗәсендә Югары Ослан үзәк район хастаханәсендә барлык үткәрелә торган УЗИ тикшерүләренең 34 проценты түләүле нигездә башкарылуы ачыкланган. Шул ук вакытта чират булмавы, аппаратларның тулы куәтенә эшләмәве беленгән.

Гражданнар шикаятьләре бушлай медицина ярдәме күрсәтүдән баш тарту, бушлай күрсәтелергә тиешле медицина ярдәме өчен акча алу белән бәйле. Еш кына алар гражданнарның гарантияле бушлай медицина хезмәте күрсәтү күләме турында, табиб-белгечләр консультацияләре, диагностика инструменталь һәм лаборатор тикшеренүләр күрсәтүне көтүнең билгеләнгән норматив сроклары турында җитәрлек мәгълүматлы булмавы аркасында килеп чыга.

Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте Территориаль фонды үткәргән, медицина учреждениеләре стендларында һәм сайтларында урнаштырылган мәгълүматлар мониторингы Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминияте эшчәнлеге алып баручы медицина учреждениеләреннән тикшерелгән 167 медицина оешманың бары 11ендә генә (6,6 процент) кирәкле мәгълүмат тулысынча урнаштырылуын, ә 148 медицина оешмасында мәгълүматның искерүен яки тулы булмавын, 8 медицина оешмасының сайтлары булмавын күрсәткән.

Элегрәк Вәкил шулай ук халыкка түләүле медицина хезмәте күрсәткәндә хокук бозулар, медицина учреждениеләрендә урнаштырылган гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына ярашлы рәвештә медицина ярдәме күрсәтү шартлары, тәртибе һәм күләме турында мәгълүматларның тулы күләмдә булмавы хакындагы мәсьәләләрне яктыртты.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм кагыйдәләрен саклау, мәҗбүри медицина иминияте чикләрендә хезмәт күрсәтелә торган һәм түләүле нигездә хезмәт күрсәтелә торган пациентлар агымын төгәл бүлү, тиешле тикшерү чаралары үткәрү юлы белән медицина учреждениеләре эшчәнлеге мониторингын тормышка ашыру буенча контрольне көчәйтү максатка ярашлы булыр иде.

Татарстанстат мәгълүматлары буенча, республикада кан әйләнеше органнары, туберкулез, ана һәм бала үлеме буенча үлемнәрнең бераз кимүе күзәтелә. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, кайбер муниципаль берәмлекләрдә үлем күрсәткечләре арту күзәтелә. Балалар үлеме буенча Чүпрәле, Актаныш, Әгерҗе муниципаль районнарында, кан әйләнеше системасы авырулары буенча Кайбыч, Чүпрәле, Тукай, Актаныш муниципаль берәмлекләрендә, туберкулез буенча Лаеш, Яңа Чишмә, Лениногорск, Әгерҗе муниципаль берәмлекләрендә күрсәткечләр югары. Инсульттан вафат булучылар Кайбыч, Алексеевск, Югары Ослан, Яшел Үзән, Апас, Әлмәт, Яңа Чишмә муниципаль районнарында күбрәк. Инфарктан үлүчеләрнең иң югары күрсәткечләре Спасс, Әлки, Бөгелмә, Лаеш муниципаль районнарында теркәлгән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы халыкның үлеме проблемасын 2014 елның август аенда коллегия утырышында карап, аңа ныклы игътибар бирде. Халыкның үлемен киметү максатыннан, республиканың муниципаль районнарында үлем мониторингын активлаштыру өлешендә, кан тамырлары үзәкләре эшчәнлеген тикшерүне үткәрү, госпитализациядән баш тарту нигезлелеге, туберкулезның соң диагностикасы очракларын анализлау, туберкулезны иртә ачыклау буенча медицина оешмалары эшен камилләштерүдә тәкъдимнәр кертү буенча мөһим идарәчел карарлар кабул ителде.

Шуның белән бергә, Вәкил фикеренчә, коллегиянең кан әйләнеше системасы авыруларының беренче билгеләре турында, кичектергесез ярдәм

күрсәтү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү буенча эшне активлаштыру турындагы карар киң таралыш алмады. Мондый нәтиҗә массакүләм мәгълүмат чараларында, турыдан-туры медицина учреждениеләрендә бу эш сизелмәгәнгә күрә ясалды. Бу уңайдан потенциаль аудиторияне арттыру юнәлешендә, халыкка киңрәк мәгълүмат бирүне тәэмин итү өчен массакүләм мәгълүмат чаралары, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау һәм медицина учреждениеләре сайтлары мөмкинлекләрен киңрәк файдалану мөһим.

Шунысын да ассызыкларга кирәк, 2015 ел Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин юлламасында йөрәк-кан тамырлары авырулары белән көрәш елы буларак билгеләнде. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, инсультлар һәм инфарктлар профилактикасы буенча чаралар алдагы елларда сәламәтлек саклау органнары эшендә иң мөһиме булырга тиеш.

2014 елда федераль дәрәҗәдә гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, яман шешләр, склероз белән авыручыларны, органнары һәм тукымалары күчереп утыртылган затларны тәэмин итү өчен билгеләнгән дару препаратлары исемлеге яңартылды һәм киңәйтелде. Кызганычка каршы, Россия Федерациясе тарафыннан федераль бюджет акчасына дарулар белән тәэмин ителүче сирәк(орфан) авырулары исемлеге киңәйтү исемлегенә эләкмәде.

Вәкил адресына узган елда сирәк(орфан) авыруларыннан җәфаланучы Татарстан Республикасы кешеләрен медицина күрсәткечләре буенча дару препаратлары белән тәэмин итүгә булышлык итү мәсьәләсе буенча гражданнардан мөрәҗәгатьләр килү дәвам итте. Әлеге проблема элеккечә үк актуаль булып кала.

Татарстан Республикасында 2014 елның беренче гыйнварына федераль регистрның төбәкара сегментына 18 сирәк(орфан) авырулары белән җәфаланучы 468 кеше кертелгән, 2014 елның беренче декабренә аларның саны арткан һәм 486 кеше булган.

Аларны дәвалау өчен елына 853,5 миллион сум акча таләп ителә.

Чыгымнарны 2020 елга кадәр бәяләү аның белену фаразыннан, авыру стадиясеннән чыгып, авыру төренә бәйле рәвештә исәпләнгән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматына караганда, күрсәтелгән сумма арту ягына сизелерлек үзгәреп, шул исәптән, яңа ачыкланган пациентлар саны арту хисабына елына 2 миллиард сумга җитәргә мөмкин.

Бюджеттан финанслау җитәрлек булмау шартларында гражданнарның дару белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча суд органнарына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булу очраклары күзәтелә.

Шул ук вакытта Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе мәгълүматы үзенә җәлеп итә, аңа ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан медицина(тормыш) күрсәткечләре буенча дару препаратлары белән тәэмин итү буенча суд карарларын үтәтү административ чаралар кулланганнан соң гына мөмкин. Сирәк авырудан җәфаланучы бер пациент файдасына булган башкару эше кысаларында, кирәкле дару препаратлары белән тәэмин итү буенча чаралар 50 000 сум күләмендә башкару җыемын алу турында карар чыгарганнан һәм бурычлыны административ җаваплылыкка тартканнан соң гына кабул ителгән. Бу факт бюджет акчалары җитмәү дару препаратлары белән тәэмин итмәүнең бердәнбер сәбәп түгел икәнен күрсәтә. Вәкил фикеренчә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына башкару эше кысаларында суд карарларын ирекле рәвештә үтәү тактикасын эшләргә кирәк. Шул исәптән, суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән берлектә эшләү зарур.

Беренче звено дәрәҗәсендә күрсәтелә торган медицина ярдәме сыйфатын күтәрү, сирәк(орфан) авырулар белән җәфаланучы гражданнарны дарулар белән тәэмин итү, 2014-2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча Стратегиядә билгеләнгәннәргә ирешү, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясе карарларын, башка идарәчел карарларны тормышка ашыруда, сәламәтлек саклау

органнарының агымдагы эшчәнлегендә чагылыш табарга тиеш.

## Социаль яклау һәм халыкны саклау

2014 елда социаль яклау һәм халыкны саклау өлкәсендә республика территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекен саклау турында әйткәндә, барыннан да элек, үткән чорның Украинадагы трагик вакыйгалар белән бәйле катлаулы булуын билгеләп үтәргә кирәк. Күрше дәүләттә сәяси хәлнең кискенләшүе уңаеннан Россия Федерациясен, шул исәптән, безнең республиканы вакытлыча яшәп тору урыны итеп сайлаган кешеләр саны сизелерлек артты. Вакытлыча яшәп тору урыны бирүне сорап Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә һәм аның территориаль бүлекчәләренә 4668 кеше мөрәҗәгать итте, бу 2013 елдагы мөрәҗәгатьләр саныннан (50 мөрәҗәгать) йөз тапкыр артып китә. Шулардан 4631ен Украина гражданнары биргән.

Хакимият органнары, җирле үзидарәләр органнары гражданлык җәмгыяте институтлары һәм битараф булмаган татарстанлылар белән бергәләп ирексездән катлаулы тормыш хәлләренә юлыккан кешеләргә оператив булыша алдылар. Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы идарәсе һәр муниципалитетта миграция хәле мониторингы буенча территориаль комиссияләр төзү, Украина гражданнары өчен вакытлыча яшәп тору пунктлары ачу, аларны үз статусын легальләштерү һәм кирәкле ярдәм алу мөмкинлекләре турында актив хәбәр итү, шулай ук кискенләшү чорында булу вакытын каршылыкларсыз озынайту буенча кирәкле чаралар кабул иттеләр. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы учреждениеләре 4571 мөрәҗәгать буенча Украина гражданнарына ашыгыч һәм планлы медицина ярдәме күрсәттеләр. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы булышлыгы белән УФМСка вакытлыча тору урыны сорап

мөрәҗәгать иткән (3005 кеше) хезмәткә яраклы Украина гражданнарының 77,5 проценты эшкә урнаштырылды. Мәгариф һәм фән министрлыгы Украинаның Татарстан Республикасы территориясенә килгән балигъ булмаган гражданнарын мәгариф учреждениеләренә урнаштыру буенча эш башкарды. Мәктәп яшендәге балаларның 99,6 проценты гомум белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларына укырга керде.

Шуның белән бергә, социаль яктан аз якланган төр гражданнарның пособие алуларын тәэмин итү, социаль тәэминат, социаль яклау чаралары күрсәтү мәсьәләләрен хәл иткәндә проблемалар һәм эшләп җиткермәүләр дә бар.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы пенсионерларын санатор-курорт дәвалау путевкалары белән тәэмин итү актуаль булып кала. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, граждан-пенсионерлардан санатор-курорт дәвалау путевкасы сораган мөрәҗәгатьләр саны (2014 елда – 10150 гариза) алына торган путевкалар саныннан шактый артып китә. ( 2014 елда – 1600 путевка).

Әлеге шартларда путевкаларны бүлгәндә гражданнар канәгатьсезлеген булдырмау, шул исәптән үзләрен алданган дип хис итмәсеннәр өчен, электрон система кертү юлы белән чагыштырмача ачык итү мөһим булып тора.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында сәламәтлеге чикләнгән 320 мең кеше яши, шулардан 14,5 меңе – инвалид-балалар. Махсус җиһазланган объектлар, транспорт һәм хәрәкәт маршрутларына мохтаҗ кешеләрнең саны арта, бу Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына социаль инфраструктура проблемаларын хәл итүнең әһәмиятле булуын күрсәтә.

Татарстан Республикасында федераль һәм республика бюджетларыннан финансланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1023 нче 23 декабрь 2013 ел карары белән расланган «2014-

2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарын социаль яклау» программасының 2014-2015 елларга исәпләнгән «Уңайлы тирәлек» өстәмә программасы тормышка ашырыла.

Программа инвалидлар эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрен үз эченә ала һәм сәламәтлек саклау, социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү, мәдәният, физик культура һәм спорт, һөнәри белем бирү объектларын аларга җайлаштыру буенча чаралар үткәрүне күздә тота. Инвалидларны реабилитацияләү һәм җәмгыятьтә интеграциясе өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән чаралар җыелмасын тормышка ашыру, инвалидлар һәм аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәрне социаль, транспорт һәм инженер инфраструктурасы һәм хезмәтләр белән тәэмин итү, аларның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, әлеге төр гражданнарның төрле өлкәләрдә (сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль тәэминат һәм башкалар) хокукларын турыдан-туры тормышка ашыруны йөкли.

Кызганычка каршы, практикада каршылыксыз мохит инвалидлар һәм аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәр өчен каршылыкларсыз формалашмый.

Узган елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән гаризаларны анализлау җир асты һәм җир өсте җәяүлеләр кичүләрен тиешенчә тотмау фактлары булуын раслый. (Яктырту булмау, «Җир асты җәяүлеләр кичүе» билгеләре, пандуслар булмау, бордюрларның биек булуы, тактиль плиткаларын сыйфатсыз урнаштыру). Аларның кайберләре битараф булмаган гражданнар мөрәҗәгать иткәннән соң гына хәл ителде.

Казан шәһәренең Комаров һәм Карбышев урамнарындагы җир өсте кичүләрендә урнашкан лифтлардан инвалидлар файдалана алмый, чөнки аларга карата вандаллык гамәлләре кылынган, шунлыктан күтәрү җайланмалары яраксыз хәлгә килгән. Зарарланган җиһазларны сатып алу һәм монтажлау өчен подрядчы оешма тарафыннан чаралар күрелде, әмма лифтларны эшләп җибәрү вакыты запас частьлар китертү вакытына бәйле булганлыктан, шактый сузылды.

Вәкил Казан муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Казан шәһәре автомобиль юлларында «Туктау тыелган» юл билгеләре кую турында»гы 882 нче 14 февраль 2014 ел карарын кабул иткәннән соң килеп туган хәлгә игътибарны юнәлтә.

Аны кабул иткәннән соң беренче һәм икенче төркем инвалид-машина йөртүчеләр мөһим функцияләр үтәүче дәүләт һәм башка учреждениеләрдән шактый ераклыкта туктарга мәҗбүр.

Җирле үзидарә органы автотранспорт өчен парковкаларда инвалидлар өчен махсус тукталу урыннары каралуын исәпкә алып, инвалид-машина йөртүчеләр өчен рөхсәт бирүче билге урнаштыруга нигез юк дип саный.

Вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләрне, массакүләм мәгълүмат чараларында басылган хәбәрләрне тикшерү барышында инвалидлар өчен урынның гади яки хезмәт транспорты тарафыннан алынуы, кайбер очракларда расланды. Күрәсең, тоталь контроль дә инвалид-машина йөртүчеләрнең хокукларын кагылгысыз саклауны тәэмин итә алмый.

1968 елның 8 ноябрендә Венада кул куюда Россия Федерациясе дә катнашкан юл хәрәкәте турындагы Конвенцияне тулыландыручы Европа килешүе кушымтасының 18 пунктында эчке законнар хәрәкәтләнергә мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларга аларның транспорт чараларын тукталу тыелган дәүләт автоюлларына куярга яки тукталып тору вакыты чикләнгән вакыттан озагракка куеп торырга рөхсәт итәргә мөмкин диелә.

Каршылыксыз мохит тудыру дәүләт сәясәтен көчәйтү максатында җирле үзидарә органнары беренче һәм икенче төркем инвалид-машина йөртүчеләргә һәм андый инвалидларны һәм инвалид-балаларны йөртүчеләргә тукталу тыелган урыннарга машина белән туктап торуда ярдәм итә алыр иде.

Элеккечә үк Вәкилнең узган еллардагы докладларында күрсәтелгән тернәкләндерү техник чаралары белән үзвакытында тәэмин итмәү проблемасы бар. Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2014 елда тернәкләндерү техник чарасы сорап мөрәҗәгать иткән 67421 кешенең 22037се тәэмин ителмәгән. Тернәкләндерү

техник чарасын үзләре алган 5702 кешедән 668е компенсация алмаган.

Инвалидларны тернәкләндерү техник чаралары белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы “Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге” электрон формада оешмалар – аукционнар(конкурслар) җиңүчеләре белән ачык аукционнар (конкурслар) нәтиҗәләре буенча төзелгән дәүләт контрактлары чикләрендә тормышка ашыра.

Асылда, тернәкләндерү техник чаралары сатып алынмаган яки хезмәт күрсәтү тормышка ашырылмаган яки тернәкләндерү техник чаралары сатып алу процедурасы яки хезмәт күрсәтү булмаган, шуңа инвалидлар тернәкләндерү техник чаралары белән тулы күләмдә тәэмин ителмәгән.

Законда инвалидлар тиешле тернәкләндерү техник чарасын мөстәкыйль рәвештә алырга мөмкин, диелә. Тернәкләндерү техник чарасы белән тәэмин итү турында инвалидларны, аларның гаилә әгъзаларын киң таныштыру булмаганлыктан, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына кирәкле техник чаралар белән тәэмин итү мөмкинлеге булмаганда, инвалидлар, опекуннар белән мөстәкыйль алу мөмкинлеге, компенсация күләме турында аңлату эшләрен көчәйтергә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр өлкәсендә законнар нигезләмәләренә ярашлы рәвештә, техник чараларга(әйберләргә) заказны урнаштыру барышында игълан ителгән әйбернең бәясенә туры килә торган бәядән тернәкләндерү техник чараларының якынча исемлеге турында мәгълүмат бирүдә гражданнарга булышлык итү буенча чаралар күрергә кирәк.

Узган ел дәвамында Вәкил адресына даими рәвештә муниципаль берәмлекләр һәм шәһәр округлары опека һәм попечительлек органнары эше белән бәйле мөрәҗәгатьләр керде.

Әйтик, Яшел Үзән муниципаль районында яшәүче законга ярашлы рәвештә опекунның аның тәрбиясендәге кешенең мөлкәтен саклау, файдалану һәм мөлкәте белән идарә итү турында хисап бирү мәсьәләсе белән

мөрәҗәгать итте. Ул үз тәрбиясендәге кешеләр белән ерак торак пунктларында яшәүче опекуннарның законны үтәү өчен район үзәгендә урнашкан опека һәм попечительлек органына хисап бирү өчен кагыйдә буларак, даими карауга мохтаҗ үз тәрбиясендәге кешеләрне калдырып китү буенча кыенлыклар туу турында белдерде.

Хисаплар бирү буенча бурычларны үтәүдә булышлык итү максатыннан Вәкил Яшел Үзән муниципаль район башкарма комитетына опека һәм попечительлек органының хисапларны опекуннар яшәгән авылларга барып алуы тәкъдиме белән мөрәҗәгать итте. Әлеге тәкъдим яклау тапты.

Әлеге тәҗрибә Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләрендә дә кулланыла ала. Урынга чыгулар опекуннарның үз тәрбиясендәге кешенең мөлкәтен саклау, файдалану һәм мөлкәте белән идарә итү турында хисаплар бирү вакытына туры китереп оештырыла ала. Шулай ук опекун тәрбиясендәге кешенең яшәү шартларын, опекуннар тарафыннан тәрбиясендәге кешенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларның мөлкәтен саклануын тәэмин итү, шулай ук опекуннар яки алар тәрбиясендәге кешеләр хокукларын һәм бурычларын тормышка ашыруга таләпләрнең үтәлешен тикшерү яхшы булыр иде.

Кабул ителгән чаралар опекуннарга үз вазифаларын каршылыксыз үтәргә һәм урында кирәкле методик ярдәм алырга мөмкинлек бирәчәк.

## Хезмәткә чакырылучыларның һәм хәрбиләрнең хокукларын яклау

2014 елда хәрби хезмәт узу өлешендә законнарда берничә мөһим үзгәрешләр кертелде, шунлыктан армиягә чакырылышта беркадәр үзенчәлекләр булды. Республикадан 30 хәрби хезмәткә чакырылучы чакырылыш буенча ашыгыч хезмәт узмыйча гына контракт буенча хезмәт итү мөмкинлегеннән файдаландылар. 2015 елның гыйнвар башына әлеге хәрбиләрдән берсе дә контрактны вакытыннан элек өзмәгән. Шулай итеп, чакырылучылар өчен контракт хезмәте институты барлыкка килүне уңай күренеш дип бәяләргә була.

Тулаем алганда, Татарстан Республикасында 2014 елда гаскәрләргә 8238 кеше җибәрелде. 516 егет (чакырылыш пунктларына килүчеләрнең 5,9 проценты) медицина күрсәткечләре буенча хәрби хезмәт үтәргә җибәрелмәде. 2013 елда 799 хәрби хезмәткә чакырылучы җибәрелмәгән иде, алар республика чакыру пунктларына килүчеләрнең ун процентына якын иде. Шулай итеп, ел саен йөзләрчә яшь егетләрнең хокукларына кагылучы медицина тикшеренүе сыйфаты күрсәткечләре кимемәде.

Вәкил, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле яшь егетләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына хәрби хезмәт урыннарына җибәрелмичә калган гражданнарның санын киметү буенча чаралар күрергә кирәк.

Вәкил хәрби частьларда булганда хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга медицина тикшеренүе уздыруның җитәрлек булмавын ачыклады. Мисал өчен, соңгы көзге чакырылыш вакытында Карачай-Черкессия Республикасында Казан шәһәре һәм Арча районыннан чакырылган ике хәрбинең веналары варикоз киңәю кискенләшкән. Булган проблемалары турында алар чакырылыш чаралары үтү вакытында ук хәбәр иткәннәр, әмма операция урынына аларны армиягә озатканнар. Хәзерге вакытта ике хәрби дә хәрби госпитальдә операция ясауны көтә. Түбән Кама

районыннан Карачай-Черкессия Республикасына чакырылган икенче хәрби хезмәткәр дә 2014 елның июлендә имгәнгән уң табанының баш бармагы булмаган килеш хезмәткә җибәрелгән, аның да физик көчәнеш вакытында сәламәтлеге начараю күзәтелгән.

Тулаем алганда, 2014 елда  сәламәтлеге начараюы сәбәпле, 4 кеше хәрби хезмәттән вакытыннан алда җибәрелгән. 2013 елда алар  алты булган.

Хезмәткә чакырылучыларның хәрби хезмәткә чакырылыш буенча чараларга мөнәсәбәтен, армия хезмәте  турында күзаллавын һәм  аларны кызыксындырган башка мәсьәләләрне өйрәнү өчен Вәкил язгы чакырылыш вакытында Татарстан Республикасы Чакырылыш пунктында булган 600 хәрби хезмәткә чакырылучы арасында сораштыру үткәрде.

Алынган мәгълүматларны анализлау йомгаклары шуны күрсәтә: хәрби хезмәткә җибәрелер алдыннан җыелу пунктында булган армиягә баручыларның күбесе хәрби бурычын оптимизм белән кабул итә. Бу этапта чакырылучыларның  92,5 проценты армиядә хезмәт итәргә теләге булуы турында белдерә. Шул ук вакытта һәр чакырылучы диярлек хәрби хезмәт узу мәсьәләләре буенча  билгеле бер дәрәҗәдә белемгә ия. Шуның белән бергә, хәрби хезмәтне үтәү, хәрби белгечлек, яңа белемнәр алу  чакырылучыларның яртысы өчен диярлек актуаль булып кала. Моннан тыш, хәрби хезмәт турында мәгълүматы  булган яшь егетләрнең (97,2 проценты) өлеше, армиядә хезмәт итәргә теләк белдергәннәргә караганда (92,5 проценты)  югарырак. Шулай итеп, кайбер хәрби хезмәткә чакырылучылар өчен армиядә хезмәт итү турындагы мәгълүмат тискәре характерда, һәм бу хәл  яшь егетләр арасында агарту эшләре алып барганда шулай ук исәпкә алынырга тиеш.

Армиядә хезмәт итү күпчелек хәрби хезмәткә алынучылар өчен барыннан да элек, тормышта  яңа белемнәр һәм осталык алу дип кабул ителә, шулай ук  вакытта тормышының киләчәге торган  бер чоры дип түгел, бары сәламәтлекнең физик торышын яхшырту кебек кабул итә. Шуның белән бергә, республиканың ике зур шәһәрләреннән килгән егетләр өчен  армия хезмәтен  социаль мобильлек каналы итеп кабул итү хас. Моны

сораштырылган казанлыларның яртысы һәм һәр икенче Чаллы егете билгеләп үткән. Казанда сораштырылганнарның 43,5 проценты һәм Чаллыдан 40,3 проценты карьера үсеше һәм контракт буенча хезмәт итү мөмкин дип саный. Армиядә бер ел хезмәт итүне карьера үсеше өчен югалту дип санау 11,3 процент казанлыга һәм 5,7 процент Чаллы егетләренә хас. Шунысын да билгеләргә кирәк, 18-19 яшьлекләрне "югалган" ел турында турындагы фикер аз борчый.

Низаглы хәлләр туганда сораштырылучыларның 58,1 проценты үз проблемалары турында сөйләргә әзер. Хәрби хезмәткә чакырылучыларның күбесендә часть командованиесенә ышаныч зур. Үз чиратында үз хокуклары бозылу һәм чакырылыш чаралары барышындагы кимчелекләр турында респондентларның 46,9 проценты күрсәткән. Сораштырылучылар җавапларын анализлау кайбер муниципаль берәмлекләрдә "җирле проблемалар" булуы турында сөйли. Хәрби комиссариатлар хезмәткәрләре һәм медицина хезмәткәрләренең мөнәсәбәтеннән шәһәрдә яшәүчеләр, чаллылардан кала, авыл кешеләренә караганда күбрәк зарланган. Белгечлек алу өчен РОСТО ДОСААФка мәҗбүри рәвештә җибәрделәр, дип белдергән армиягә баручы егетләрнең дә өлеше тигез түгел. Әлеге проблемаларны билгеләп үткән яшь егетләрнең күбесе армиядә хезмәт итәргә теләге барлыгын белдергән, шуңа аталган кимчелекләр һәм хокук бозуларны уйлап чыгарылган дип нәтиҗә ясарга ярамый, шуңа муниципаль берәмлекләрдәге хәрби комиссариатлар бүлекләренә тискәре очракларны булдырмау өчен превентив чаралар күрергә кирәк.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты бүлекләре хезмәткәрләренә хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм контракт буенча хезмәт итәргә теләүчеләр арасында аңлату эшләрен алып барырга кирәк.

## Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын яклау

Федераль законнарга ярашлы рәвештә, мәҗбүри тоту урыннары эшчәнлегенә контроль функцияләрен үтәп, Вәкил һәм аның аппараты пенитенциар системада кеше хокукларын яклау һәм саклау мониторингын тормышка ашыра. Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләрендә һәм тикшерү изоляторларында, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының махсус учреждениеләрендә һәм Федераль миграция хезмәте Татарстан Республикасындагы идарәсенең чит ил кешеләрен һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту учреждениеләрендә була.

Җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә булу барышында хөкем ителгәннәрне казарма тибындагы биналардан кайнар суы, аерым санузелы һәм душ кабинасы булган аз урынлы торак секцияләренә планлы күчерү баруын, видеокүрешүләр, электрон почта һәм гаепләнүчеләргә һәм хөкем ителгәннәргә ашамлыклар тапшыру заказлары өчен интернет-кибеттән файдалану мөмкинлекләре кертелүне билгеләп үтәргә кирәк.

Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе системасы учреждениеләрендә медицина хезмәте күрсәтүдә алга китеш күзәтелә. 2 нче төзәтү колониясенең хөкем ителгәннәр өчен хастаханәсе бүлекләрендә һәм палаталарында ремонт эшләре тәгәлләнде, авырулар өчен яңа диагностика аппаратурасы алынды. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ярдәме белән хөкем ителүчеләр өчен хастаханә республика клиник хастаханәсенең Ситуация үзәгенә тоташтырылды, бу аның алдынгы белгечләренә онлайн-режимында консультацияләр үткәрү мөмкинлеге бирә һәм сак астында тотылган затларга сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлекләрен сизелерлек киңәйтә.

Әмма медицина бүлекчәләрен матди-техник яктан тәэмин итү яхшыруга карамастан, төзәтү учреждениеләрендә үлем күрсәткече югары

булып кала. Мәсәлән, 2014 елда авырулардан үлүчеләр 55 кеше, 2013 елда 41 кеше булган. Туберкулездан үлүчеләр саны арткан (2014 елда – 9 кеше, 2013 елда – 4 кеше). Шул ук вакытта хөкем ителгәннәрнең үлеме структурасында туберкулез кан әйләнеше органнары авыруларына караганда (29 процент) аз урын алып тора. ВИЧ-инфекция белән авыручылар – 17,4 процент.

Әлеге тискәре күренешләр фонында, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе учреждениеләреннән Россия Федерациясе Җинаять кодексының 81 нче маддәсенә ярашлы рәвештә, җәза үтәүгә комачаулык тудыручы каты авыру сәбәпле хөкем ителгәннәрне җәза үтәтүдән азат итү турында судларга җибәрелгән 11 юллама күп түгел. Вәкил җәзаларны үтәүгә комачаулык итүче авырулары булуы хакында карарлар кабул итәрдәй затларны ачыклау буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе медицина бүлекчәләренең эшен көчәйтү кирәк дип исәпли. Каты авырулар аркасында азат итү турында судка юлламалар саны төзәтү системасы учреждениеләрендә туберкулез, кан әйләнеше органнары авырулары, ВИЧ-инфекциядән үлүчеләргә карата күбрәк булырга тиеш.

2014 елда төзәтү учреждениеләрендә туберкулез белән авыручылар саны 2013 ел белән чагыштырганда 8,2 процентка артып, 144 кешене тәшкил итте. 2015 елның 1 гыйнварына барысы Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең 1 нче дәвалау төзәтү учреждениесендә актив туберкулезлы 316 кеше бар. Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең медицина системасында дәвалану үткәннән соң хөкем ителгәннәр дәваланган булып исәпләнә, җәзаларны үтәтү урыннарына җибәрелә, алар анда интенсив күзәтү астында була һәм кирәкле диетик туклану ала. Авыру дәваланыла ала дип исәпләнә, ләкин туберкулез белән авырган кешенең кабат зарарлану куркынычы бар. Начар шартларда һәм авырулар белән кабат элемтәдә булганда алар кабат авырырга мөмкин.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тәкъдимнәре буенча һәр хөкем ителүченең туберкулезга дөрес диагностика куюга һәм дәвалауга

чикләнмәгән хокукы булырга тиеш, алга таба инфекцияне таратмас һәм туберкулезны үзбелдеклеләнеп дәвалауга юл куймас өчен, туберкулез белән авыру очракларын тиз ачыклап, дәвалау мөһим.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының күрсәтелгән тәкъдимнәрен тормышка ашыру максатларында, төзәтү системасы учреждениеләрендә авыруны кабатламас өчен туберкулездан дәваланган затларга медикаментоз профилактика уздыруга аерым игътибар бирелергә тиеш.

2014 елда иректән мәхрүм итү урыннарында 11 кеше үз-үзенә кул салган.(Шундый ук хәл 2013 елда кабатланган). Әлеге фактлар буенча прокуратура органнары махсус контингентның сәламәтлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җаваплы вазифаи затларның эшендә кимчелекләр булуын ачыклады. Шул ук вакытта 9 хөкем ителүче аутоагрессив күренешләргә дучар затлар буларак психологларда профилактик исәптә торган. Бу уңайдан суицид очракларына юл куймас өчен, суицид һәм үз-үзенә кул салырга сәләтле кешеләр буларак профилактик исәпкә куелган затларга карата нәтиҗәле тактик контроль булдыру кирәк. Суицид кылган ике кешенең исәптә тормавын искә алып, үз-үзенә кул салырга сәләтле кешеләрне ачыклау буенча эшне көчәйтергә кирәк.

Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен саклау турында Конвенциянең 3 нче маддәсендә ирегеннән мәхрүм ителүчеләр аларның кешелек сыйфатын хөрмәт иткән шартларда тотылып, җәза үтәгәндә бу чараны үтәү ысулы аңа сак астында булганда тиешледән артык кыенлыклар китерергә тиеш түгеллеге әйтелә. Моннан тыш, иректән мәхрүм ителү белән бәйле практик таләпләрне исәпкә алып, хөкем ителгән кешенең сәламәтлеге һәм уңай яшәеше сакланырга тиеш. Шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләне сак астында тоту турында халыкара нормалар һәм Россия законнары нигезләмәләре принципларына ярашлы рәвештә, сак астында тоту урыннардагы хакимият шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләрнең сәламәтлеген саклауны тәэмин итүче санитар-гигиена таләпләрен үтәргә бурычлы.

Республиканың тикшерү изоляторлары тиешле нормадан уртача 1 проценттан 2,1 процентка кадәр тулган. 2015 елның беренче гыйнварына Чистай шәһәренең 5 нче СИЗОсында 571 кеше тотылган, бу учреждениедә тотылырга тиешледән 49 кешегә артык. Бөгелмә шәһәренең 3 нче СИЗОсында лимит 40 кешегә артык. Казан шәһәренең 1 нче һәм 2 нче СИЗОларында тиешледән 29 һәм 25 кә күбрәк тоткын тотыла.

2014 елда Вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә хөкем ителүчеләрне мондый шартларда тотарга ярамавы турында хатлар җибәрде. Аларны карау нәтиҗәләре һәм прокурор актлары нигезендә лимитны арттыруга юл куймау өчен чаралар күрелде. Әмма ел дәвамында СИЗОда тотылган затларның күп тапкырлар мөрәҗәгать итүен, Вәкилнең тоту шартларының канәгатьләнмәслек булуы фактларына игьтибарын исәпкә алып, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә хәбәр ителгән факт принцибы буенча гына эшләмичә, оператив идарә карарлары да кабул итәргә кирәк.

Хөкем ителгәннәрне иреккә чыккач урнаштыру кебек проблемалы аспектларга тукталып, Вәкил иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән яки азат ителәчәк хөкем ителүчеләргә яшәп тору урыннары, торак бирү, теркәлү турында төзәтү учреждениеләреннән эчке эшләр органнарына җибәрелгән мөрәҗәгатьләрне тикшерүдә уңай үзгәрешләр күзәтелмәвен билгеләп үтә.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе тәкъдим иткән мәгълүматларга караганда, 2014 елда эчке эшләр органнарына җибәрелгән запрослар саны арткан һәм 3198не тәшкил иткән. Алар 2013 елда 2857 булган). 2014 һәм 2013 елларда җибәрелгән мөрәҗәгатьләрнең 15 проценты җавапсыз калган. Хөкем ителүченең элекке яшәү урынына кайту мөмкинлеге турында мәгълүматлар булмау иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән хөкем ителүчеләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартларын оештыру мәсьәләләрен хәл итүне кыенлаштыра.

Вәкилгә хөкем ителүчеләрдән килгән язмача мрәҗәгатьләрне карау барышында, шулай ук Вәкилнең төзәтү учреждениеләрендә булуы вакытында хөкем ителүчеләрдән кергән сорауларның берсе – иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәч дәүләт тарафыннан яклау гарантияләре булмау. Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең махсус учреждениеләре үткәрә торган җәза үтәүче затларның документларын булдыру, эшче белгечлекләренә өйрәтү, азат ителгәннән соң тормышка яраклаштыруда психологик әзерлек хөкем ителүчеләрне тормыш итүгә әзерләүнең мөһим шарты булып тора.

Хезмәт базары үсү шартларында хөкем ителүчеләрне төзәтү учреждениеләрендә һөнәргә өйрәтү аларда эшләүче производство мәнфәгатьләрен генә исәпкә алып башкару практикасыннан китәргә кирәк, аларның эшкә талантын, киләчәктә эшкә урнашу мөмкинлеген күздә тотып эшләү мөһим. Элеккеге хөкем ителгәннәрне гражданлык җәмгыятендә тулы кыйммәтле тормышка кайтаруда аларның төзәтү учреждениеләрендә алган көндәшлеккә сәләтле һөнәри квалификациясе мөһим фактор булып тора. Хәзерге шартларда эшкә урнашу өчен бер генә белгечлек һәм эш тәҗрибәсе булу гына җитми, еш кына эшкә кандидаттан компьютерны белүе, финанс документларын алып бара белүе таләп ителә. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәрдән бары 347 кеше генә эш тапкан. (Мөрәҗәгать итүчеләр саныннан 53 процент).

Бу уңайдан Краснодар крае тәҗрибәсе кызыклы, анда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең җирле идарәсе һәм төбәк эшмәкәрләре теләктәшлегендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләр өчен тернәкләндерү үзәге ачылган. Психологик һәм социаль ярдәмнән тыш, үзәктә элеккеге хөкем ителүчеләр компьютерга өйрәнү курсларын үтәләр, аларга маркетинг, иктисад һәм хисап эше буенча лекцияләр укыйлар. Ә соңыннан үзәккә йөрүче гражданнар үз эшен ачу буенча бизнес-проектлар әзерлиләр, алга таба аларга идеяләрен тормышка

ашыру өчен ярдәм күрсәтелә. Булачак бизнесменнарны өйрәтүнең моңа охшаш программасы әлеге төбәкнең төзәтү учреждениеләрендә дә тормышка ашырыла.

Мондый тәҗрибәне безнең республикада кертү җәза үтәгән кешеләрнең үз эшен алып бару мөмкинлекләрен киңәйтергә булышып, азат ителгәннән соң эш урыны тапмаган һәм кабат җинаять кылган гражданнар санын кыскартыр иде.

Татарстан Республикасына килгән чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукларын саклау да мөһим булып тора.

Суд карарына ярашлы рәвештә административ чыгарып җибәрү яки депортация турында карар кабул ителгән чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар урнаштырыла торган, Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту махсус учреждениесендә булганда Вәкилгә махсус учреждениедә тоту шартларына игътибар итүне сорап мөрәҗәгать итәләр.

Учреждениегә урнаштырылган кешеләр илдән чыгарып җибәрүне уртача бер айдан өч айга кадәр көтәләр, шул ук вакытта аларга кием, аяк киеме, алмаш урын-җир кирәк яраклары бирү законда каралмаган. Россия Федерациясе хөкүмәтенең 1306 нчы 2013 елның 30 декабре карарында каралган матди-көнкүреш тәэминаты нормалары Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту учреждениесенә урнаштырылган чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен әйберләр белән тәэмин итүне күздә тотмый, бу чит ил гражданнарының Вәкилгә белдергән шикаяте булып тора. Әйтик, Таҗикстаннан килгән Р.ны урамда Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре тоткарлаган һәм ул суд карары буенча махсус учреждениегә урнаштырылган, монда ике ай илдән чыгарып җибәргәннәрен көткән, алмаш кием алу өчен акчасы булмаган, аңа

кием бирердәй туганнары һәм дуслары да булмаган. Махсус учреждениенең хакимиятенә аңа үз көчләре белән ярдәм итәргә туры килгән.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә, Татарстан халыклары Ассамблеясе советының башкарма комитетына махсус учреждениедә тотылган чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны матди-көнкүреш әйберләре белән тәэмин итү өчен акча табу, шул исәптән ирекле хәйриячелек хисабына тәэмин итү мөмкинлекләрен карарга кирәк.

## Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкил эшчәнлегендә хокукый агарту

Вәкилнең кеше һәм граждан хокуклары һәм иреге өлкәсендә хокукый агартуга булышу, кеше хокуклары өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне тормышка ашыруга ярдәм итү буенча эше дәвам итә.

Вәкилнең халыкны хокукый агарту буенча эше профиль белем бирү процессы һәм җәмгыятьтә тиешле хокукый белемнәр таратуны оештыру өчен җаваплы дәүләт органнары эшен алыштыра алмый, әмма аны тулыландыра.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкил каршындагы «Хокукый белем бирү мәктәбе» чикләрендә гражданнар өчен, актуаль темалар буенча төрле максатчан аудиторияләр өчен чаралар актив тормышка ашырыла. Шулай ук Вәкилнең социаль партнерлары катнашында гомумроссия иҗтимагый оешмасы – «Россия пенсионерлар берлеге»нең Татарстандагы төбәкара бүлеге белән берлектә оештырыла торган «Хокукый ярдәм көне» үткәрү дә, халык тарафыннан хупланып кабул ителә.

2014 елда «Хокукый белем бирү мәктәбе»нең 4238 тыңлаучы өчен барлыгы 24 дәресе үткәрелде, шул исәптән 8 дәрес – өченче буын университеты тыңлаучылары өчен, 10 зона дәресе – хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм аларның ата-аналары өчен, 6 дәрес – «ЖКХ» факультатив курсын тыңлаучылар өчен. 11 «Хокукый ярдәм көне»

барышында Казан, Буа, Яшел Үзән шәһәрләрендә яшәүче 456 кеше консультатив ярдәм алды.

Вәкилнең халыкка хокукый белем бирү һәм бушлай юридик белем күрсәтү өлкәсендәге эш тәҗрибәсен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы рәисе Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр һәм шәһәр округлары башлыкларына эшләрендә куллану өчен тәкъдим итте.

Муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында бушлай юридик ярдәм күрсәтү һәм хокукый агарту нәтиҗәле системасын булдыру, законнарның интенсив үсеше сәбәпле халыкны хокукый агарту җитмәү, системалы һәм актуаль хокукый мәгълүматның җитәрлек булмавы сәбәпле кирәк.

Муниципаль районнарда (шәһәр округларында) халыкны хокукый агарту буенча үткәрелә торган эш турында безнең адреска килгән мәгълүматлар буенча түбәндәгеләрне билгеләргә мөмкин.

Гражданнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтү чикләрендә күпчелек муниципаль районнар территорияләрендә район җитәкчелеге, төрле учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан гражданнарны атна саен кабул итү үткәрелә. Азнакай, Әлмәт, Апас, Бөгелмә, Зәй, Кайбыч, Кукмара районнарында «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлегенең җирле бүлекчәләре иҗтимагый кабул итү бүлмәләрендә бушлай юридик белем алу мөмкинлеге билгеләп үтелә.

Бушлай юридик хезмәте телдән һәм язмача консультация бирү рәвешендә, гаризалар, шикаятьләр, юлламалар төзү рәвешендә күрсәтелә. Әлмәт, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе муниципаль районнарында районнарның башкарма комитетлары һәм советларының, башка структураларның «кайнар линия»ләре эшли. Актаныш, Әлмәт, Балтач, Зәй, Балык Бистәсе районнарында өлкәннәр декадасында, инвалидлар үнкөнлегендә бушлай юридик хезмәт күрсәтү көннәре уздырыла.

Азнакай, Актаныш, Алексеевск, Әлмәт, Арча, Бөгелмә, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Менделеев, Мөслим, Яңа Чишмә, Түбән Кама, Нурлат, Питрәч, Теләче, Ютазы муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә халыкның нотариусларда һәм адвокатларда бушлай юридик консультацияләр алу мөмкинлеге бар. Вәкилнең гражданнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтүне күпфункцияле үзәкләр күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлегенә кертү турындагы тәкъдиме тормышка ашырыла. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәгълүматлары буенча, гражданнар Татарстан Республикасының 24 муниципаль берәмлегендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрендә адвокатлар хезмәтләреннән файдалана ала.

Халыкка хокукый мәгълүмат бирү максатында Әлмәт, Зәй, Кукмара, Мамадыш, Чирмешән районнары җирле газеталарында һәм рәсми сайтларында муниципаль актлар урнаштырыла. Азнакай, Әлмәт, Мөслим муниципаль районнары газеталарында гражданнарны хокукый агарту буенча даими рубрикалар бар, кайбер материаллар Әлмәт, Бөгелмә, Түбән Кама җирле телевидениесе һәм радиосы аша җиткерелә.

Шунысын да әйтергә кирәк, күпчелек муниципаль берәмлекләрдә хокукый агарту буенча чараларның күбесе үсеп килүче буынны рухи-хокукый тәрбияләүгә юнәлтелгән. Болар – мәгълүмати һәм танып-белү сәгатьләре, хокук, әхлак дәресләре, әңгәмәләр, күргәзмәләр, яшь сайлаучылар көннәре. Мәгариф учреждениеләрендә шулай ук ришвәтчелек белән халыкара көрәш көненә багышланган планлы чаралар үткәрелә, аның кысаларында укучыларның хокук саклау органнары вәкилләре белән очрашулары, класс сәгатьләре, «түгәрәк өстәл» утырышлары, китап күргәзмәләре, иншалар, рәсемнәр бәйгеләре оештырыла. Бирелгән мәгълүматларга караганда, Актаныш, Әлмәт, Апас, Баулы, Балтач, ЯшелҮзән, Кама Тамагы, Кукмара, Балык Бистәсе, Саба, Спасс, Чистай районнарында һәм Казан шәһәрендә планлы рәвештә Россиякүләм балаларга хокукый ярдәм көннәре үтте.

Мәктәп укучылары белән үткәрелә торган эшнең мөһимлеген киметмичә, Вәкил халыкның башка катлавы белән дә актив эш алып барырга кирәклеген билгеләп үтә.

Гражданнар торак үзидарәсенең яңа формасы буларак, күпквартирлы йортлар советлары институтлары барлыкка килү чорында гражданнар белән аралашуның уңай тәҗрибәсе Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә бар, биредә күпквартирлы йортлар советлары, торак милекчеләре ширкәтләре һәм торак кооперативлары җитәкчеләре катнашында махсус эшләнгән һәм расланган программа буенча бушлай семинарлар үткәрелә.

Муниципаль районнарга халык белән очрашуларны, шул исәптән хокук саклау органнары, социаль яклау органнары, Пенсия фонды, төрле оешмалар вәкилләре катнашында даими оештырып, халыкны хокукый агартуга тагын да җитдирәк игътибар бирергә, Вәкил кулланган «Хокукый ярдәм күрсәтү мәктәбе», «Хокукый ярдәм көне» дәресләрен оештырырга кирәк. Халык белән шундый формада очрашулар югары профилактик кыйммәткә ия, чөнки очрашуларда гражданнарны борчыган мәьәләләргә җавап бирергә, шулай ук халык өчен актуаль проблемаларны ачыкларга була, бу аларны хәл итүгә районнар җитәкчеләре игътибарын юнәлтергә мөмкинлек бирә.

«Хокукый белем бирү мәктәбе» дәресләре форматы бары Әлки, Азнакай, Аксубай, Апас, Баулы, Зәй, Кама Тамагы, Лаеш, Мөслим, Сарман, Теләче районнарында гына кулланыла, халык өчен «Хокукый ярдәм көне» Лаеш, Нурлат, Тәтеш районнарында үткәрелә.

Яшьләрне хокукый агарту; урта махсус һәм югары уку йортлары укучыларын (студентлар) хокукый агарту; эшләүче халыкны аларның эшчәнлеген исәпкә алып хокукый агарту; авыл җирләрендә яшәүче халыкны хокукый агарту; өлкән яшьтәге кешеләрне хокукый агарту; аз тәэмин ителгән һәм башка социаль яктан аз якланган кешеләрне хокукый агарту; мигрантларны һәм гражданлыгы булмаган затларны хокукый агарту; пенитенциар учреждениеләрдә булган затларны хокукый агарту –

муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында күрсәтелгән эшнең төп юнәлешләре булырга тиеш.

Шулай итеп, җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре белән бергә, халыкны хокукый агарту идеяләрен активрак пропагандаларга һәм тормышка ашырырга, республика халкын хокукый агартуда һәм хокукый грамоталык үсеше мәсьәләләрендә җирле үзидарә органнарының халык белән актив эш оештыруына юнәлтелгән өстәмә чараларны кабул итәргә кирәк. Бу юнәлештә төрле эш формалары кулланып, бушлай юридик ярдәм күрсәтү системасын үстерү зарур.

## Йомгак

2014 елда булган макросоциаль дәрәҗәнең катлаулыкларына карамастан, Татарстанда кеше һәм граждан хокуклары һәм иреге кысылмады. Республика хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының халык алдындагы социаль йөкләмәләре кимемәде. Торак һәм социаль әһәмиятле объектларны төзү, сәламәтлек системасын үстерү, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү, халыкның аз якланган катлавына социаль яклау чаралары күрсәтү буенча бурычлар хәл ителде. Тормышның мөһим өлкәләрендә кеше хокукларын тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар эшләнүче һәм тормышка ашырылучы «2014-2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегия» 2014 елның 2 августында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 569 нчы карары белән расланды.

Шуның белән бергә республика территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекен яклау һәм саклау буенча эш йомшармаска тиеш. Татарстанлылар икътисадтагы катлаулыклар чорында үзләрен якланмаган дип хис итәргә тиеш түгел.

Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә элеккечә үк эш хакын вакытында түләмәү проблемасы кала. Хакимият һәм җирле үзидарәләр органнары

бергәләшеп эшләргә тиешләр. Оешмаларның штаты һәм хезмәткәрләре саны кыскару сәбәпле эштән җибәрелгән гражданнарның хокукларын саклау һәм яклауның өстәмә механизмнары актуаль. Җитештерүдә үлем белән тәмамланган бәхетсезлекләр белән хәл катлаулы булып кала.

Торак төзү һәм төзелеш темплары югары булуга карамастан, республикада яшәүчеләрнең торак шартларын яхшырту проблемасы үз актуальлеген югалтмый. Социаль найм килешүе буенча торак бүлмәләре бирү буенча эшне оештыру нәтиҗәле булырга тиеш. Ятим балалар һәм ана-ана кайгыртуыннан мәхрүм балаларның торакка хокукларын тормышка ашыруга ныклы игътибар бирелергә тиеш. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтү өлкәсендә компетентлы дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына идарәче оешмаларның персональ мәгълүматлар турында законнны үтәү буенча эшенә ныклы игътибар бирергә кирәк. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүне киметү өчен максатчан субсидияләр сорап мөрәҗәгать иткән гражданнар белән актив аңлату эшләре алып бару мөһим.

Дәүләт гарантияләре программасы кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәмен түләүле хезмәтләргә алыштыруга юл куймау – сәламәтлек саклау системасы бурычларыннан берсе. Кан әйләнеше системасы авырулары вакытында кискен хәлнең беренче билгеләре турында, ашыгыч ярдәм күрсәтү чаралары турында халыкның мәгълүматлы булуы дәрәҗәсен күтәрү таләп ителә. Сирәк (орфан) авырулардан җәфаланучы кешеләрнең хокукларын тәэмин итү мөһим.

Санатор-курорт путевкалары белән тәэмин итүдә пенсионерларны социаль яклау чаралары буенча эш, шулай ук инвалидларны тернәкләндерү техник чаралары белән тәэмин итүдә хокукларын тормышка ашыру ачык булырга тиеш. Нәтиҗәле социаль сәясәтне закон тәртибендә билгеләнгән, эшкә яраксыз дип танылган гражданнарга ярдәм һәм инвалидлар өчен каршылыксыз мохит үсешендә алга бара торган хәрәкәттән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Татарстанның гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүдәге алдынгы урыны хәрби хезмәткә чакырылучыларга медицина тикшеренүе уздыру буенча сыйфатлы эш белән бәйләнгән булырга тиеш.

Пенитенциар система учреждениеләрендә медицина ярдәме күрсәтү һәм көнкүреш белән тәэмин итү, иректән мәхрүм урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру проблемалары да актуаль булып кала.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазифаи затларның Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирегeн яклау принципларын хөрмәт итүенең аерылгысыз бер өлеше, ул халыкны хокукый агарту. Хокукый нигилизмны җиңеп чыгу буенча чаралар мөһим.

Әйтелгәннәрне исәпкә алып, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирeгeн саклау һәм яклауны көчәйтү максатында, Вәкил дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнары һәм вазифаи затларга түбәндәге чараларны күрергә тәкъдим итә.

1. Хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә кеше һәм граждан хокукларын тормышка ашыру максатында:

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел 10 август 676 нчы карарына, «Хезмәтне саклау таләпләрен бозу» дигән өстәмә төрне булдыру хакында үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карарга.

1.2. Татарстан Республикасы профсоюзлар федерациясенә, республиканың тармак профсоюз органнарына, Татарстан Республикасы эш бирүчеләре координацион советына оешманың (шәхси эшмәкәр) хезмәткәрләр саны яки штаты кыскару белән хезмәт килешүен өзүе турында карар кабул ителгән хезмәткәрләр гаризалары буенча, алга таба бу төр хезмәткәрләрнең хезмәткә хокукларын бозуны киметүгә, шул исәптән

законсыз эштән җибәрү турында суд тәртибендә канәгатьләндерелгән дәгъвалар санын киметүгә юнәлтелгән карарлар эшләү буенча эш бирүчеләрнең хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр эшен оештыру турындагы мәсьәләне карарга.

1.3. Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының мәшгульлек хезмәте органнарына, оешманың (шәхси эшмәкәр) хезмәткәрләре санын яки штатын кыскарту планлаштырылган предприятиеләр(оешмалар) консультацион пунктлары кысаларында үткәрелгән чаралар йомгаклары буенча хезмәт законнарын бозу турындагы мәгълүматларны контроль-күзәтчелек органнарына һәм хокук саклау органнарына тапшыру буенча эшне оештырырга кирәк.

1.4. Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясенә эш хакы түләү буенча бурычлары булган оешмалар саны һәм муниципаль берәмлектә хуҗалык итүче субъектлар гомуми саны нисбәтеннән, тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм табышларны легальләштерү буенча территориаль комиссияләр рейтингына индикатор күрсәткечләре кертү мәсьәләсен карарга.

1.5. Җирле үзидарә органнарына:

хезмәткәрләргә эш хакы түләү буенча бурычларны бетерүдә тулы чаралар кабул итмәүче оешмалар турында мәгълүматларны чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясенә һәм прокуратура органнарына тапшыру буенча эшне активлаштырырга;

тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм табышларны легальләштерү буенча ведомствоара комиссия эше кысаларында мәшгульлек органнары белән бергәләп эш хакы буенча бурычларга, шул исәптән хезмәткәрләрнең саны яки штат кыскару аркасында эштән җибәрелә торган хезмәткәрләргә ( әгәр бурычлы оешма шундый карар кабул иткән икән) компенсация, шулай ук бала ялында булган хезмәткәрләргә бала караган өчен пособие түләүләре өлешендә закон бозуларга юл куйган хуҗалык итүче субъектларга карата

контрольне тормышка ашырырга.

2. Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру максатларында:

2.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына аз якланган дип танылган һәм Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 ел 16 июнь 378 нче карарында күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән җәфаланучы гражданнарга социаль найм килешүе буенча торак бүлмәләре бирү буенча чаралар эшләү турындагы мәсьәләне карарга.

2.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына алар карамагындагы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балалар өчен булган учреждениеләрдә ятимнәрнең торак бүлмәләре белән тәэмин итүгә мохтаҗлыгын ачыклап, законда билгеләнгән тәртиптә торак алу өчен үзвакытында исәпкә бастыру эшен оештырырга.

2.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына ведомство сайтында торак-коммуналь хезмәтләргә бәя артуны киметүгә максатчан субсидияне исәпләү буенча халык өчен электрон калькулятор урнаштыру мәсьәләсен карарга.

2.4. Җирле үзидарә органнарына:

Муниципаль торак фонды өчен буш булган торак бүлмәләрен ачыклап, соңыннан социаль найм килешүе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга бирүне оештырырга, торак бүлү буенча торак комиссияләре эшен активлаштырырга;

Яңа гаиләләргә бирелгән ятим-балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балаларны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исемлегенә кертмәү очракларына юл куймау буенча чаралар күрергә;

Агент килешүләре (башка килешүләр) нигезендә персональ мәгълүматлар белән эшләүдә читтән оешмаларны җәлеп итүче идарәче оешмаларны мәгълүматлар бирүдән баш тарткан очракта, мәгълүматны

күзәтчелек органнарына тапшырып, персональ мәгълүматлар операторлары реестрына кертү буенча мониторинг үткәрергә.

3. Гражданнарның сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокукларын тормышка ашыру максатларында:

3.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Дәүләт гарантияләре программасы кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәмен «Ведомство контроле кысаларында беленгән халыктан нигезле шикаятьләр саны», «Контроль-күзәтчелек органнарының законлы белдерүләре саны» индикатор күрсәткечләре белән түләүле хезмәтләргә алыштыруга юл куймау буенча чараларны көчәйтергә.

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренең сайтларында түләүсез медицина ярдәменең гарантияләнгән күләме турында, табиб-белгечләрнең консультацияләрен, диагностика инструменталь һәм лаборатор тикшеренүләрне көтүнең билгеләнгән норматив вакытлары турында тулы мәгълүмат урнаштыру, актуальләштерү буенча эшен оештырырга.

Кан әйләнеше системасы авырулары вакытында кискен хәлнең беренче билгеләре турында, потенциаль аудиторияне арттыру юлы белән кичектергесез ярдәм күрсәтү чаралары турында республика халкына мәгълүмат бирү буенча эшне активлаштырырга;

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе бүлекчәләре ягыннан административ тәэсир чаралары кабул иткәч кенә, сирәк(орфан) авыруларыннан җәфаланучы гражданнарны дару белән тәэмин итү турында суд карарларын үтәү очракларын бетерергә.

4. Гражданнарның социаль яклау чаралары һәм социаль яклауга хокукларын тормышка ашыру максатларында:

4.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасында пенсионерларны санатор-курорт дәвалау белән тәэмин иткәндә путевкалар бүлүнең электрон системасын кертү буенча чаралар күрергә;

Инвалидларны тернәкләндерү техник чаралары белән үзвакытында тәэмин итмәү очракларына юл куймау өчен чаралар күрергә һәм тернәкләндерү чараларын мөстәкыйль рәвештә сатып алган гражданнарга компенсация түләү тәртибе турында аңлату эшләрен көчәйтергә.

4.2. Җирле үзидарә органнарына:

Муниципаль берәмлек яки шәһәр округы чикләрендә хәрәкәт итәргә мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларның, мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны яки инвалид балаларны йөртүче автомобильчеләрнең транспорт чаралары өчен тукталу тыелган урыннарны киметү мәсьәләсен карарга;

Ерак авылларда яшәүче, закон тәртибендә эшкә яраксыз дип танылган гражданнар опекуннарның хисапларын урыннарга чыгып алу буенча опека һәм попечительлек органнары эшен оештыру турындагы мәсьәләне карарга.

5. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле яшь егетләрнең хокукларын саклау максатында, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына медицина күрсәткечләре буенча республика чакырылыш пунктында хәрби хезмәт үтү урынына җибәрүдән калдырылган гражданнар санын киметү буенча чаралар күрергә.

6. Мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затларның хокукларын саклау максатында:

6.1. Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә:

төзәтү системасы учреждениеләрендә ВИЧ-инфекция, кан әйләнеше системасы авырулары, туберкулездан үлемнәр санына каты авыру аркасында хөкем ителүчене азат итү турында судка юлламалар саны нисбәтенә индикатор күрсәткече белән, җәза үтәүгә комачаулык итүче авырулары булу

турында заключениеләр кабул ителергә мөмкин булган затларны ачыклау эшен көчәйтергә;

махсус контингент авырулары рецидивын киметү очраклары индикатор күрсәткече белән, авырулар рецидивына юл куймау максатында туберкулездан дәваланган затларга медикаментоз профилактикасы буенча чараларны көчәйтү мәсьәләсен карарга;

суицид кылырга яки үз-үзенә кул салырга мөмкин булган зат буларак профилактик исәпкә куелган кешеләргә контрольне тормышка ашыруның нәтиҗәле ысуллары турындагы мәсьәләне карарга;

Татарстан Республикасында урнашкан төзәтү учреждениеләренә кертү максатыннан, хөкем ителгәннәрне эшмәкәрлек күнекмәләренә өйрәтү буенча Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү мәсьәләсен карарга.

6.2. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән хөкем ителүчеләргә яшәп тору урыннары, торак бирү, теркәлү турында төзәтү учреждениеләреннән эчке эшләр органнарына җибәрелгән мөрәҗәгатьләр буенча полиция бүлекләренең мәгълүмат бирмәве очракларына юл куймаска.

6.3. Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә Татарстан халыклары Ассамблеясе Советының башкарма комитеты белән берлектә Россия федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту учреждениесенд чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны матди-көнкүреш әйберләре белән тәэмин итү өчен акча табу, шул исәптән ирекле хәйриячелек хисабына тәэмин итү мөмкинлекләрен карарга кирәк.

7. Республика халкын хокукый агарту максатларында:

7.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасының комплекслы үсешен тәэмин итү өлкәсендә эшне алга таба камилләштерү буенча чаралар күрергә, гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу мөмкинлекләре турында мәгълүмат алуына булышлык итәргә,

гражданнарның хокукый белемнәрен арттыру буенча яңа эш формалары булдырырга,Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм һәм хокукый агарту системасы үсеше мониторингын тормышка ашырырга.

7.2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына халыкның түләүсез юридик алу мөмкинлеге турындагы мәгълүматны һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) хокукый агарту буенча уңай эш тәҗрибәсе турындагы мәгълүматны таратырга.

7.3. Җирле үзидарә органнарына республикада яшәүчеләрне хокукый агарту һәм хокукый грамоталык үсеше мәсьәләләрендә төрле эш формаларын кулланып һәм массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итеп, Вәкил тәҗрибәсен, шулай ук югары уку йортлары, аларның филиаллары, югары уку йортлары каршындагы юридик клиникалар, җәмәгать оешмалары, профиль учреждениеләре мөмкинлекләрен файдаланып, халыкның төрле катлаулары белән актив эшләүне оештыруга юнәлтелгән чаралар күрергә.

**Татарстан Республикасында**
**Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил** **С.Х. Сабурская**

2015 ел, февраль

**ДОКЛАД УПОЛНОМОЧЕННОГО ПО ПРАВАМ ЧЕЛОВЕКА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН**

**О СОБЛЮДЕНИИ ПРАВ И СВОБОД ЧЕЛОВЕКА И ГРАЖДАНИНА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
В 2014 ГОДУ**

Аппарат Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан
Адрес: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

Отпечатано в типографии «ЗурКазан».
Тираж 250 экз.
420095, г. Казань, ул. Серова, 4а
Тел.: (843) 253-58-33

***

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ**

**2014 ЕЛДА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ
ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН САКЛАУ ТУРЫНДА**

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты
Адрес: 420015, Казан ш., К. Маркс ур., 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

«ЗурКазан» типографиясендә нәшер ителде
Тираж 250 данә.
420095, Казан ш., Серова ур., 4а
Тел.: (843) 253-58-33